АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА
им. Г. ИБРАГИМОВА

**Э. И. САФИНА**

# ТАТАРСКО-РУССКО-ЛАТИНСКИЙ СЛОВАРЬ ОРНИТОНИМОВ

КАЗАНЬ • 2018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исем.
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

**Э. И. САФИНА**

# ТАТАРЧА-РУСЧА-ЛАТИНЧА КОШ АТАМАЛАРЫ СҮЗЛЕГЕ

КАЗАН • 2018

**УДК 81′374.823**
**ББК 81.2Тат-4**
**С 24**

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Гыйльми советы карарына нигезләнеп басыла*

«2014 – 2020 елларда Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында нәшер ителә

**Фәнни редакторы**
филология фәннәре докторы **А.Ә. Тимерханов**

**Бәяләүчеләре:**
биология фәннәре докторы **И.И. Рәхимов,**
филология фәннәре докторы **Ә.Ш. Юсупова**

**Сафина Э.И.**
**С 24** **Татарча-русча-латинча кош атамалары сүзлеге** / Э.И. Сафина. – Казан: ТӘһСИ, 2018. – 184 б.
ISBN 978-5-93091-257-9

Сүзлеккә татар теленең кош атамалары һәм аларның русча, латинча гомум кабул ителгән вариантлары теркәлде. Барлык атамалар төп сүз принцибы нигезендә ояларга берләштереп бирелде. Сүзлек киң катлау укучыларга гамәли кулланма буларак тәкъдим ителә. Ул шулай ук орнитологлар, сүзлекчеләр, тәрҗемәчеләр, матбугат һәм радио, телевидение хезмәткәрләре, мәктәп укучылары, укытучылар өчен дә файдалы белешмә булып хезмәт итәчәк.

УДК 81′374.823
ББК 81.2Тат-4

**ISBN 978-5-93091-257-9**

© Сафина Э.И., 2018
© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2018

# КЕРЕШ СҮЗ

Кошлар дөньясы бай һәм күптөрле. Халыкара орнитологлар берлегенең 2016 елгы мәгълүматларына караганда, кошларның 10 660 төре билгеле. Россиядә якынча 800, Татарстанда 300 ләп кош төре исәпләнә. Үзләре күпсанлы булгач, аларны белдерүче атамаларның да шактый булуы гаҗәп түгел. Кайбер кошны атау өчен әдәби телдә берничә атама йөрүен, шуңа өстәп, еш кына халык телендә, сөйләшләрдә үзенчәлекле кош атамалары кулланылуын исәпкә алганда, бу саннар бермә-бер арта. Мәсәлән, *байгыш, мәче башлы ябалак, ихахай ябалак, төнге ябалак, чырайсыз ябалак, өке* һ.б. орнитонимнарның барысы да бер үк кошны белдерә. Атамалары актив кулланышта икән, димәк, фәнни, әдәби һәм халык телендәге орнитонимнарның барысын да туплап, системага салып, аларны төгәл тәрҗемәләр белән теркәгән сүзлек тә гаять актуаль хезмәтләрдән саналырга хаклы.

«Татарча-русча-латинча кош атамалары сүзлеге» моңа кадәр басылган биологик, терминологик, аңлатмалы, икетелле, диалекталь сүзлекләргә, энциклопедияләргә, авторның кош атамаларын өйрәнүгә багышланган фәнни хезмәтендәге сүзлекчәгә, кошларга бәйле махсус белешмәлекләргә таянып эшләнде. Хезмәтнең төп өлешен 1700 дән артык орнитоним, 255 ояга (аның эчендә 99 оячык) туплап бирелгән 1610 әдәби, 113 диалекталь кош атамасы тәшкил итә.

Сүзлек материалының төп өлеше Россиядә, Татарстанда очрый торган кошларның атамаларыннан гыйбарәт. Шул ук вакытта, башка илләрдә яки аерым континентларда гына тереклек итә торган кошларның исемнәрен сүзлеккә кертми калдыру да дөрес булмас иде, чөнки һәр шәһәрдә диярлек зоопарклар, кош күргәзмәләре һ.б. эшләп торган бүгенге заманда хәтта *тәвә кошы, тутый кош, фифи, фламинго, эму, нанду* кебек экзотик

кошлар да күпләргә таныш. Туган як фаунасы өчен ят булган мондый кошлар, гадәттә, чит телдән кергән исеме белән атап йөртеләләр. Сүзлектә андый алынма атамаларның күпчелеге, мөмкин булганча, татар теле җирлегендә ясалган сүзләр белән алыштырылды яки телнең әйтелеш һәм язылыш нормаларына яраклаштырып тәкъдим ителде.

Татар телендә орнитонимнар системасының эшләнеп, тәртипкә салынып бетмәве исә теге яки бу кошны белдерү өчен татарча орнитоним кулланылмавы һәм, киресенчә, кайбер кошларны төрлечә атау нәтиҗәсендә барлыкка килгән буталчыклык белән бәйле. Мәсәлән, рус телендә *снегирь* дип йөртелә торган кошны татарлар *кызылтүш* дип тә, *карабүрек* дип тә атыйлар. Бу орнитонимнар хәтта сүзлекләрдә дә төрлечә теркәлгән. Моның сәбәбе бик гади: кеше әйләнә-тирәсендәге тереклек ияләренә яисә төрле предмет-күренешләргә аларны аерып торган берәр сыйфатыннан чыгып исем бирә. *Кызылтүш* (зяблик) тә, *карабүрек* (снегирь) тә янып торган кызыл түшле булулары белән игътибарны җәлеп иткәнгә күрә, аларның һәр икесен *кызылтүш* дип атау еш күзәтелә. Чыпчыкларның *зарянка* дигән төрен берәүләр *кура җиләге чыпчыгы* дип атасалар, икенчеләр, таң вакытында сайравын исәпкә алып, *таң чыпчыгы* дип йөртәләр һ.б. Димәк, орнитонимнарның төрлелеге кошларга хас характерлы билгеләрнең күп булуына, лингвистик һәм экстралингвистик факторларга бәйле. Бер яктан, бер үк предметның яки җан иясенең берничә атама белән белдерелүе туган телнең байлыгын күрсәтсә, икенче яктан, аларның исемен сүзлекләрдә төрлечә бирүгә китерә. Кайбер кош атамаларының вариантлары биш яки алты, сөйләшләрдә актив кулланыла торганнарын да исәпкә алганда, уннан да артып китәргә мөмкин. Сүзлектә аларның халык телендә аеруча еш кулланылганнарына гына урын бирелде. Шул ук вакытта, кош атамалары системасының байлыгын күрсәтү максаты белән, әдәби телгә хас орнитонимнардан тыш, төрле шивәләрдә кулланыла торган атамаларны бирү дә кирәк дип табылды. Алар әдәби телдәге атамадан соң китерелде һәм сүзлек ахырында алфавит тәртибендәге исемлек рәвешендә урын алды.

Әлегә кадәр татарча сүзлекләрдә рус телендәге *крачка* да, *чайка* да *акчарлак* дип йөртелсә, *оляпка, олуша, сутора, чистик, улит, фрегат* кебек кошларның татар телендәге атама-

лары гомумән юк иде. Рус телендә яисә башка төрки телләрдә кабул ителгәнчә, *песнәк, карчыга* кебек кошларның төрләрен белдерү өчен дә, татарча махсус орнитонимнар кулланылмады. Кош атамаларын сүзлекләргә теркәү өлкәсендәге мондый эзлексезлек, системасызлык алфавит тәртибендә төзелгән икетелле, терминологик һ.б. сүзлекләрдә артык сизелмәде, ә менә һәр орнитонимны төп сүз оясында биргән очракта, атамаларның төгәл, ачык яңгыравы таләп ителә. Орнитонимнарны аерым ояларга бүлгәч, рус телендәге *тиркушка*, *веретенник*, *песочник* дип йөртелә торган кошларның барысын да, элегрәк басылган сүзлекләрдәге кебек, *шөлди* дип биреп булмый, чөнки *шөлди* рус теленә *кулик* дип тәрҗемә ителә. Мондый уртак исемле кошлар күп һәм аларны шул килеш кенә сүзлектән сүзлеккә күчерә барырга да мөмкин булыр иде. Әмма рус һәм күп кенә төрки телләрдә аерым атамасы бар икән, искиткеч бай татар телендә дә аларның һәммәсенә туры килерлек, үзенә генә хас сыйфатына таянып атарлык орнитонимы булырга тиеш. Шуны исәпкә алып, әлеге сүзлек «атамасыз» шактый орнитонимнарның татар телендә яңгырашын булдыру бурычын күз уңында тотып эшләнде. Теге яки бу кошның характеристикасын өйрәнеп һәм аның үзенчәлекле билгеләренә игътибар итеп, башка төрки телләрдәге терминнар белән чагыштырып, нәкъ менә әлеге кошны тасвирлый торган сыйфатны исемдә чагылдырырга тырышып сайланган андый атамалар татар теленең орнитонимнар системасындагы җитешсезлекләрне киметергә ярдәм итәр дип уйлыйбыз.

Кошларга атама сайлаганда, төп игътибар халык телендәге һәм сөйләшләрдәге вариантларга юнәлтелде. Моңа мисал итеп акчарлак кошлар семьялыгындагы татар телендә атамасы булмаган *говорушка* кошына, әлеге кошлар чыгарган авазларга бәйле рәвештә, *бытылдавык* дип исем бирүне, *тетерев*ны да, *куропатка*ны да *көртлек, урман тавыгы* дип бер төрле атаудан качар өчен, *тетерев*ны башка төрки телләрдә һәм татар телендә кулланыла торган *озан* сүзе белән атауны һ.б. китерергә була. *Деряба, зонотрихия, олуша, чистик, крохаль* кебек тәрҗемәсез атамаларны да сүзлеккә автор тарафыннан тәкъдим ителгән *баркылдык, кәләпүшле чыпчык, ишкәгаяк, ишкәкканат, игәүборын* кебек татарча вариантта теркәү уңышлырак дип уйларга нигез бар.

Сүзлектән файдаланучыга өстәмә мәгълүмат бирү максаты белән, Татарстанда һәм Россиядә очрый торган кошлар махсус билгеләр белән аерып күрсәтелде, семьялык һәм отряд исемнәре, кошлар белән бәйле сынамышлар, мәкаль-әйтемнәр китерелде.

Моңа кадәр кулланылган атамаларны системага салып, кайбер алынма орнитонимнар урынына татар теленә ятышлы исемнәр тәкъдим итеп төзелгән әлеге сүзлек, орнитологлар, биологлар, сүзлекчеләр, тәрҗемәчеләр, укытучылар, телчеләр өчен генә түгел, гади кулланучы өчен дә файдалы һәм мәгълүматлы чыганак булып хезмәт итәчәк.

Сүзлекнең эчтәлегенә карата фикер-тәкъдимнәрегезне түбәндәге адреска юллый аласыз:

420111, Казан шәһәре, К. Маркс урамы, 12 йорт,
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 5 нче бүлмә.

Электрон почта адресы: iyali.anrt@mail.ru

## СҮЗЛЕКНЕҢ ТӨЗЕЛЕШЕ

1. Сүзлектә орнитонимнар оя рәвешендә урнаштырылды: башта төп атама (мәсәлән, **КАЗ**), аннан соң алфавит тәртибендә составында әлеге сүз булган башка орнитонимнар (**Ак маңгайлы каз** Гусь белолобый *Anser albifrons*, **Соры каз** Гусь серый *Anser anser*, **Ындыр казы** Гуменник *Anser fabalis* һ.б.) санап кителде. Орнитонимнарны оялап бирү аларны белдергән кошларның барысы да бер семьялыктан яки бер отрядтан дип уйларга нигез була алмый, атамаларны, беренче чиратта, төп сүз берләштерә. Кайбер очракларда оя эчендә дә оя(лар) аерып чыгарылды. Мәсәлән, шул ук **КАЗ** оясында **ДИҢГЕЗ КАЗЫ** Гагара яисә **КЫЗЫЛКАЗ** Фламинго оячыклары һ.б. бар. Кечкенә оядa бер генә орнитоним булырга да, алфавит тәртибендә шул төркемгә караган берничә атама бирелергә дә мөмкин. Мәсәлән:

**КАЗ** Гусь

**Ак башлы каз**^Т^**, акбаш, су тавыгы** *к.* кашкалак

**Ак каз**^Р^ Гусь белый *Anser caerulescens (Chen caerulescens)* һ.б.

**ДИҢГЕЗ КАЗЫ, гагара** *к.* гагара

**Ак муенлы диңгез казы**^Р^**, ак муенлы гагара** Гагара белошейная *Gavia pacifica* һ.б.

**ТУНДРА КАЗЫ, казарка** Казарка

**Ак яңаклы тундра казы**^Т^**, ак яңаклы казарка** Казарка белощёкая *Branta leucopsis* һ.б.

2. Оядагы һәр термин яңа юлдан язылып, иң элек төп орнитоним һәм аның русчага тәрҗемәсе китерелде (мәсәлән, **КАРГА** Ворона). Төп орнитоним төр исеме булганда аның фәндә кабул ителгән латинча термины да бирелде. Вокабуладан гыйбарәт төп орнитонимнан соң семьялык һәм отряд исемнәре

күрсәтелде. Сүзлекчеләр һәм орнитологлар җайлы гына куллана алсын өчен, алар 91–94 битләрдә алфавит тәртибендә аерым исемлек итеп тә бирелде. **Отряд исемнәре** түбәндәге модель буенча ясала: **орнитоним + сыман + нар** (*бабакошсыманнар* – пеликанообразные, *казсыманнар* – гусеобразные, *кәсвәрсыманнар* – казуарообразные, *тавыксыманнар* – курообразные һ.б.). **Семьялык исемнәре**нең ясалышы түбәндәгечә: **орнитоним + кошлар** (*ишкәкканат кошлар* – чистиковые, *кәккүк кошлар* – кукушковые, *тәвә кошлар* – страусовые). Орнитоним ике яки берничә компонентлы булган очракта, аңа күплек һәм тартым кушымчалары гына ялгана (*америка грифлары* – грифы американские, *бүрекле чыпчыклар* – свиристелевые, *давыл хәбәрчеләре* – буревестниковые, *әрәмә чыпчыклары* славковые һ.б.).

3. Бер үк кошның берничә атамасы булган очракта (*бәрәнкарак, бәрән карагы, сакаллы карчыга, сакалтәй, бәрән бөркете, бәрән карчыгасы*), аларның иң киң кулланылганы (*бәрән карчыгасы*) төп орнитоним буларак бирелеп, аның янәшәсендә генә бу орнитонимның тәрҗемәсе һәм латинча термины күрсәтелде. Ә бу кошны белдергән башка синоним атамалар алфавит тәртибендә үз урыннарында китерелеп, *к.* (*карагыз*) күрсәткече белән төп атамага (яки башта ояга, аннары ук билгесе белән (→) төп орнитонимга) җибәрелде. Мәсәлән:

**БӘРӘНКАРАК, бәрән карагы, сакаллы карчыга, сакалтәй, бәрән бөркете** *к.* карчыга → бәрән карчыгасы.

4. Россиядә очрый торган кошлар атамасыннан соң югары регистр белән [Р] хәрефе, Татарстан фаунасындагы кошлар исеменнән соң [Т] хәрефе куелды. Мәсәлән, **ак мыеклы әрәмә чыпчыгы**[Р], **алдагыч әрәмә чыпчыгы**[Т] һ.б. [Т] хәрефе белән бирелгәннәре һәм Татарстанда, һәм Россиядә бар дигән сүз. Ил күләмендә очраган кошларның исемлеге «Список птиц Российской Федерации» (М., 2006, 256 с.) белешмә китабына нигезләнеп бирелде.

5. Диалекталь орнитонимнарның кайсы сөйләштә кулланылуы җәяләр эчендә күрсәтелде. Бер үк сөйләшкә караган атамаларның фонетик вариантлары авыш сызык (/) белән аерылды. Мәсәлән, **барабикә / бәрәбишкә** Воробей. Барлык диалекталь орнитонимнар белән сүзлек ахырында танышырга мөмкин (156–159 б.).

6. Исеменнән гади укучыга нинди кош турында сүз баруы аңлашылмый торган сирәк очракларда, җәя эчендә әлеге кошның кайсы отрядка, семьялыкка каравы яисә нинди кошлардан булуы күрсәтелде. Мәсәлән, **ЛОРИ** Лори *Loriinae* (тутый кошлардан), **БЫТЫЛДАВЫК** Говорушка (акчарлак кошлар семьялыгыннан) һ.б.

7. *Гагара, гага* кебек алынма орнитонимнарның күп булуын исәпкә алып, мөмкин булганча аларның татарчалаштырылган атамалары теркәлде. Эзләп табарга җайлы булсын өчен, әлеге сүзлектә мондый атамаларның ике варианты да күрсәтелде: *ак томшыклы диңгез казы – ак томшыклы гагара* һ.б.

8. Теге яки бу кошның русчага тәрҗемәсен белмәгән (ягъни, нинди кош турында сүз баруын аңламаган) кулланучыга сүзлек белән эшләүне җиңеләйтү өчен, кушымта буларак, татар телендәге һәм рус телендәге төп орнитонимнарның исемлеге аерым-аерым бирелде. 95–112 битләрдәге әлеге тәрҗемәләр кошларның иң еш кулланыла торган атамаларын искә төшерергә ярдәм итәчәк.

9. Сүзлек ахырында алфавит тәртибендә терминнар күрсәткече китерелде. Ул, кошның татарча атамасын белмәгән очракта, русча атамасы аша эзләп табу мөмкинлеген күз уңында тотып, русча-татарча итеп эшләнде.

# ФАЙДАЛАНЫЛГАН ЧЫГАНАКЛАР ИСЕМЛЕГЕ

Авыл хуҗалыгы һәм урманчылык атамалары: Атамалар сүзлеге сериясеннән XI кисәк. – Казан: Татгосиздат, 1931. – 83 б.

Азбука природы: Птицы: Русско-татарский, татарско-русский словарь биологических терминов / сост. А.Б. Халидов, В.И. Гаранин. – Казань: Магариф, 2001. – 95 с.

Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге / Р.Г. Әхмәтьянов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 272 б.

Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге / Р.Г. Әхмәтьянов. Ике томда. I том (А–Л). – Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. – 543 б.

Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге / Р.Г. Әхмәтьянов. Ике томда. II том (М–Я). – Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. – 567 б.

Биологиядән русча-татарча аңлатмалы сүзлек / төзүчеләре: Ф.Г. Ситдиков, Р.К. Зәкиев, А.Б. Халидов һ.б.; ред.: Ф.Г. Ситдиков, Р.К. Зәкиев. – Казан: Мәгариф, 1998. – 664 б.

Животный мир Татарии / сост.: В.А. Попов, А.В. Лукин. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1988. – 248 с.

Михеев А.В. Биология птиц. Полевой определитель птичьих гнёзд: пособие для студентов пединститутов и учителей средних школ. – М.: Топикал, 1996. – 460 с.: ил.

Птицы Европейской России. Полевой определитель. – М.: Союз охраны птиц России; Алгоритм, 2001. – 224 с. с илл.

Птицы мира / ред. группа: К. Михайлов, Т. Евсеева. – М.: Мир энциклопедий Аванта+, Астрель, 2008. – 184 с.: ил.

Рахимов И.И., Мосалов А.А. Атлас-определитель птиц республики Татарстан. Казань, изд-во «Фолиант», 2008. – 176 с. с илл.

Русча-татарча биология терминнары сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1972. – 167 б.

Русча-татарча биология терминнары сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 198 б.

Сафина Э.И. Названия птиц в татарском языке и их лексикографирование / Э.И. Сафина. – Казань: Дом печати, 2006. – 160.

Сафина Э.И. Названия птиц в татарском языке и их лексикографирование: автореф. дис. ... канд. филол. наук: 10.02.02 / Э.И. Сафина; Казан. гос. ун-т им. В.И. Ульянова-Ленина. – Казань, 2005. – 27 с.

Список птиц Российской Федерации / Коблик Е.А., Редькин Я.А., Архипов В.Ю. – М.: Товарищество научных изданий КМК, 2006. – 256 с.

Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы: уку әсбабы / И.И. Рәхимов, К.К. Ибраһимова; русчадан Ф.Г. Ииштирәкова, Р.З. Закирова тәрҗ. – Казан: Мәгариф, 2007. – 199 б.: рәс. б-н.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге / баш ред. проф. Ф.Ә. Ганиев. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 832 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: I том: А–В. – Казан: ТӘһСИ, 2015. – 712 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: II том: Г–Й. – Казан: ТӘһСИ, 2016. – 748 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: III том: К. – Казан: ТӘһСИ, 2017. – 744 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: Өч томда / редкол.: Л.Т. Мәхмүтова, М.Г. Мөхәммәдиев, К.С. Сабиров, Ш.С. Ханбикова; СССР ФА КФ Г.Ибраһимов ис. ТӘТИ. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977–1981.

Татар теленең диалектологик сүзлеге / Л.Т. Мәхмүтова ред. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1969. – 642 б.

Татар теленең зур диалектологик сүзлеге / Төз.: Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 839 б.

Татар теленең диалектологик сүзлеге / Д.Б. Рамазанова ред. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – 459 б.

Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр (кереш мәкалә авторы Х. Мәхмүтов). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. – 592 б.

Татар халык мәкальләре (кереш мәкалә авторы һәм җыючысы, төзүчесе Нәкый Исәнбәт). Өч томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1959, 1963, 1967.

Татарская энциклопедия. Т. I–IV. Казань: Ин-т Татар. энцикл. АН РТ, 2002, 2005, 2006, 2008.

Татарско-русский словарь. Ок. 38 000 слов. – М.: Сов. Энциклопедия, 1966. – 863 с.

Татарско-русский словарь: В 2-х т. – Казань: Магариф, 2007.

Тимергалин А. Миллият сүзлеге: Аңлатмалы сүзлек / А. Тимергалин. – Казан: Мәгариф, 2007. – 575 б.

Тимергалин А. Миллият сүзлеге: аңлатмалы сүзлек / А. Тимергалин. – 3 томда. I т.: А–И хәрефләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – 783 б.

Тимергалин А. Миллият сүзлеге: аңлатмалы сүзлек. / А. Тимергалин. – 3 томда. II т.: Й–Р хәрефләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. – 684 б.

## ШАРТЛЫ КЫСКАРТЫЛМАЛАР

*ар*. – Арча ягында кулланылган
*әстр*. – әстерхан сөйләше
*бгрс*. – богырыслан сөйләше
*брб.д*. – бараба диалекты
*гәй*. – гәй сөйләше
*глз*. – нократ сөйләшенең глазов урынчылыгы
*диал*. – диалекталь сүз
*дөб*. – дөбъяз сөйләше
*злт*. – златоуст сөйләше
*к*. – карагыз
*каз.ар*. – казан арты сөйләшләре төркеме
*каз.ар.-крш*. – казан арты керәшеннәре сөйләше
*каз.ар.-лш*. – казан арты – лаеш сөйләше
*карс*. – Карсун авылы сөйләше
*клм*. – калмак сөйләше
*кргл*. – каргалы сөйләше
*кузн*. – кузнецк сөйләше
*лмб*. – ләмбрә сөйләше
*лш*. – лаеш сөйләше
*мәл*. – мәләкәс сөйләше
*минз*. – минзәлә сөйләше
*нокр*. – нократ сөйләше
*перм*. – пермь сөйләше
*саз я*. – саз ягы сөйләше
*себ*. – себер сөйләшләре

*сир*. – сирәк кулланыла (яки элек кулланылган)
*сөйл.* – сөйләм телендә
*срг*. – сергач сөйләше
*стрл*. – стәрлетамак сөйләше
*тара.* – тара сөйләше
*тбл*. – тобол сөйләше
*твр*. – тевриз сөйләше
*тмн*. – темников сөйләше
*том.д*. – том диалекты
*төм*. – төмән сөйләше
*тпк*. – тепекәй сөйләше
*трбс*. – турбаслы сөйләше
*трх.* – тархан сөйләше
*туб.-ирт.д*. – тубыл-иртыш диалекты
*урт.д*. – урта диалект
*чст.* – чистай сөйләше
*эчк.* – эчкен сөйләше
*яүшт*. – яүштә-чат сөйләше

## ТАТАР АЛФАВИТЫ

| | | | |
|---|---|---|---|
| Аа | Зз | Пп | Чч |
| Әә | Ии | Рр | Шш |
| Бб | Йй | Сс | Щщ |
| Вв | Кк | Тт | ъ |
| Гг | Лл | Уу | Ыы |
| Дд | Мм | Үү | ь |
| Ее | Нн | Фф | Ээ |
| Ёё | ң | Хх | Юю |
| Жж | Оо | Һһ | Яя |
| Җҗ | Өө | Цц | |

# А

**АГАЯК, ак аяклы чебенче** Белоножка *Enicurus scouleri*
**АЕРЫКОЙРЫК**[Т] *к.* карлыгач → кыя карлыгачы
**АКБАШ**[Т]**, ак башлы каз, су тавыгы** *к.* кашкалак
**АКБҮКСӘ**[Р]**, ак бүксәле ишкәкканат** Белобрюшка *Cyclorrhynchus psittacula*
**АККАНАТ**[Т], **ак канатлы тургай** Жаворонок белокрылый *Melanocorypha leucoptera*
**АККОШ**, *диал.* қуу / ақ қуу (*твр.*), ағош (*брб.д.*), аққу (*әстр.*) Лебедь

**Америка аккошы**[Р] Лебедь американский *Cygnus columbianus*
**Кара аккош** Лебедь чёрный *Cygnus atratus*
**Кара муенлы аккош** Лебедь черношейный *Cygnus melancoryphus*
**Кара томшыклы аккош**[Р] Лебедь-трубач *Cygnus buccinator*
**Кече аккош**[Р]**, тундра аккошы** Лебедь малый *Cygnus bewickii*
**Нәфис аккош**[Т]**, сары борынлы аккош** Лебедь-кликун *Cygnus cygnus*
**Сары борынлы аккош** *к.* нәфис аккош
**Тундра аккошы** *к.* кече аккош
**Ысылдавык аккош**[Т] Лебедь-шипун *Cygnus olor*

**АККҮЗ** Белоглазка

**АККҮЗ КОШЛАР** Белогла́зковые *Zosteropidae* (семьялык)
**Коңгырт аккүз**[Р] *к.* чыпчык → ак күзле чыпчык

**АКМУЕН**[Р]**, ак муенлы каз** Белошей *Anser canagicus*
**АКЧАРЛАК**, *диал.* ақсырдақ (*злт.*), қазыйақ (*минз.*), қәлмәргән (*туб.-ирт.д.*) Чайка

**АКЧАРЛАК КОШЛАР** Ча́йковые, чайки *Laridae* (семьялык)
**Ак акчарлак**[Р] Чайка белая *Pagophila eburnea*

**Ал акчарлак**[Р] Чайка розовая *Rhodostethia rosea*
**Бонапарт акчарлагы**[Р] Чайка бонапартова *Larus philadelphia*
**Борынгы акчарлак**[Р] Чайка реликтовая *Larus relictus*
**Гади акчарлак**[Т] *к.* күл акчарлагы
**Диңгез акчарлагы**[Т] Чайка морская *Larus marinus*
**Кара башлы акчарлак**[Р] Чайка черноголовая *Larus melanocephalus*
**Кара койрыклы акчарлак** Чайка чернохвостая *Larus crassirostris*
**Каспий акчарлагы**[Р] Чеграва *Hydroprogne caspia*
**Кечкенә акчарлак**[Т] Чайка малая *Larus minutus*
**Котып акчарлагы**[Т] Бургомистр, чайка полярная большая *Larus hyperboreus*
**Көмеш акчарлак**[Т] Чайка серебристая *Larus argentatus*
**Көнчыгыш акчарлагы**[Т] Халей (клуша восточная) *Larus heuglini*
**Көнчыгыш себер акчарлагы** Чайка восточносибирская *Larus vegae*
**Көрән башлы акчарлак**[Р] Чайка буроголовая *Larus brunnicephalus*
**Күк акчарлак**[Т] Чайка сизая *Larus canus*
**Күл акчарлагы**[Т]**, гади акчарлак** Чайка озёрная *Larus ridibundus*
**Кытай акчарлагы**[Р] Чайка китайская *Larus saundersi*
**Нәфис акчарлак**[Р] Голубок морской *Larus genei*
**Өч бармаклы акчарлак**[Р] Моевка *Rissa tridactyla*
**Поляр акчарлак**[Р] Чайка полярная *Larus glaucoides*
**Сары томшыклы акчарлак**[Т] Клуша *Larus fuscus*
**Сәнәк койрыклы акчарлак**[Р] Чайка вилохвостая *Xema sabini*
**Соры канатлы акчарлак**[Р] Чайка серокрылая *Larus glaucescens*
**Тын океан акчарлагы**[Р] Чайка тихоокеанская *Larus schistisagus*

**СУКИСӘР АКЧАРЛАК** Водорез

**Африка сукисәр акчарлагы** Водорез африканский *Rynchops flavirostris*
**Кара сукисәр акчарлак** Водорез чёрный *Rynchops nigra*

**Һинд сукисәр акчарлагы** Водорез индийский *Rynchops albicollis*

**ҮЛӘКСӘ АКЧАРЛАГЫ** Поморник

**Зур үләксә акчарлагы**[Р] Поморник большой *Stercorarius skua*

**Көньяк поляр үләксә акчарлагы**[Р] Поморник южнополярный *Stercorarius maccormicki*

**Кыска койрыклы үләксә акчарлагы**[Т] Поморник короткохвостый *Stercorarius parasiticus*

**Озын койрыклы үләксә акчарлагы**[Р] Поморник длиннохвостый *Stercorarius longicaudus*

**Уртача үләксә акчарлагы**[Т] Поморник средний *Stercorarius pomarinus*

**ШАРКЫЛДЫК АКЧАРЛАК** Хохотун

**Кара башлы шаркылдык акчарлак** Хохотун черноголовый *Larus ichthyaetus*

**АЛМАБАШ**[Т]**, алмабаш чүрәкәй, сызгырак чүрәкәй** *к.* чүрәкәй → сыбызгы чүрәкәй

**АЛЬБАТРОС** Альбатрос

**АЛЬБАТРОС КОШЛАР** Альбатро́совые *Diomedeidae* (семьялык)

**Ак аркалы альбатрос**[Р] Альбатрос белоспинный *Phoebastria albatrus*

**Илгизәр альбатрос** Альбатрос странствующий *Diomedea exulans*

**Кара аркалы альбатрос**[Р] Альбатрос тёмноспинный *Phoebastria immutabiis*

**Кара аяклы альбатрос**[Р] Альбатрос черноногий *Phoebastria nigripes*

**А́РА** А́ра

**Зәңгәр-сары ара** Ара сине-жёлтый *Ara ararauna*

**Кызыл ара** Ара красный *Ara macao*

**Сөмбел ара** Ара гиацинтовый *Anodorhynchus hyacinthinus*

**А́РГУС** Аргус

**Зур аргус** Аргус большой *Argusianus argus*

# Ә

**ӘБЕРЧЕН**[т]**,** *диал.* ала туба (*перм.*), туба (*минз.*) Вяхирь *Columba palumbus*

**Япон әберчене** Вяхирь японский *Columba janthina*

**ӘТӘЛГЕ**[т] *к.* балабан

**Гади әтәлге** *к.* балабан → гади балабан

**Европа әтәлгесе** *к.* балабан → Европа балабаны

**Монгол әтәлгесе** *к.* балабан → Монгол балабаны

**Себер әтәлгесе** *к.* балабан → Себер балабаны

**Тибет әтәлгесе** *к.* балабан → Тибет балабаны

**Төркестан әтәлгесе** *к.* балабан → Төркестан балабаны

**ӘТӘЧ,** *диал.* этәз (*каз.ар.*), этәс (*минз., глз., нокр.*), этиц (*клм.*), эцәт (*срг.*), әчәт (*чст., срг., мәл., карс.*) Петух

**Банкив әтәче, банкив тавыгы, куаклык тавыгы** Петух банкивский, курица банкивская джунглевая *Gallus gallus*

# Б

**БАБАКОШ** Пеликан

**БАБАКОШЛАР** Пелика́новые *Pelecanidae* (семьялык)

**БАБАКОШСЫМАННАР** Пеликанообра́зные *Pelecaniformes* (отряд)

**Алсу бабакош**[т] Пеликан розовый *Pelecanus onocrotalus*

**Бөдрә бабакош**[т]**, көдрәч бабакош** Пеликан кудрявый *Pelecanus crispus*

**Көдрәч бабакош**[т] *к.* бөдрә бабакош

**БАКААВЫЗ** Лягушкорот

**БАКААВЫЗ КОШЛАР** Лягушкоро́ты, совиные козодои, белоноги *Podargidae* (семьялык)

**Австралия ябалаксыман бакаавызы** Лягушкорот совиный австралийский, белоног карликовый *Aegotheles cristatus*

**Колаклы бакаавыз** Лягушкорот ушастый *Batrachostomus auritus*

**Көлсу бакаавыз** Лягушкорот дымчатый, белоног исполинский *Podargus strigoides*

**Мәрмәр бакаавыз** Лягушкорот мраморный *Podargus ocellatus*

**Соры башлы бакаавыз** Лягушкорот сероголовый *Batrachostomus poliolophus*

**Тәңкәле бакаавыз** Лягушкорот чешуйчатый *Batrachostomus stellatus*

**БАКЛАН, диңгез козгыны,** *диал.* палыкцы (*төм., тбл., брб.д.*) Баклан

**БАКЛАН КОШЛАР** Бакла́новые *Phalacrocoracidae* (семьялык)

**Беринг бакланы**[Р], **Беринг диңгез козгыны** Баклан берингов *Phalacrocorax pelagicus*

**Бүрекле баклан**[Р], **бүрекле диңгез козгыны** Баклан хохлатый *Phalacrocorax aristotelis*

**Зур баклан**[Т], **зур диңгез козгыны** Баклан большой *Phalacrocorax carbo*

**Зур колаклы баклан**[Р], **зур колаклы диңгез козгыны** Баклан ушастый *Phalacrocorax auritus*

**Кечкенә баклан**[Р], **кечкенә диңгез козгыны** Баклан малый *Phalacrocorax pygmaeus*

**Кызыл йөзле баклан**[Р], **кызыл йөзле диңгез козгыны** Баклан краснолицый *Phalacrocorax urile*

**Стеллер бакланы**[Р], **Стеллер диңгез козгыны** Баклан стеллеров *Phalacrocorax perspicillatus*

**Япон бакланы**[Р], **Япон диңгез козгыны** Баклан японский *Phalacrocorax capillatus*

**БАЙГЫШ, мәче башлы ябалак, зур колаклы ябалак, ихахай ябалак, чырайсыз ябалак, төнге ябалак,** *диал.* бабалаш (*перм.*), үгү (*тбл.*), қарабылқы (*том.д.*), филим (*нокр.*), өкө (*перм., злт.*), өкө йабалагы (*тпк.*), өхө (*саз.я.*), ихахай җабалақ (*дөб.*) Филин *Bubo bubo*

**Аксыл байгыш** Филин бледный *Bubo lacteus*

**Африка байгышы** Филин африканский *Bubo africanus*

**Балык байгышы**[Р] Филин рыбный *Ketupa blakistoni*

**Гвинея байгышы** Филин гвинейский *Bubo poensis*

**Көнбатыш Африка байгышы** Филин западноафриканский *Bubo leucostictus*

**Непал байгышы** Филин непальский *Bubo nipalensis*

**Соры байгыш** Филин серый *Bubo cinerascens*

**Филиппин байгышы** Филин филиппинский *Bubo philippensis*

**Чүл байгышы** Филин пустынный *Bubo ascalaphus*

**БАКЫЛДЫК**[р] Ква́ква *Nycticorax nycticorax*

**Япон бакылдыгы**[р] Кваква японская, выпь японская *Gorsachius goisagi*

**Яшел бакылдык**[р] Кваква зелёная *Butorides striatus*

**БАЛАБАН**[т], **этәлге** Балобан *Falco cherrug*

**Гади балабан, гади этәлге** Балобан обыкновенный *Falco cherrug cherrug*

**Европа балабаны, Европа этәлгесе** Балобан европейский *Falco cherrug danubialis*

**Монгол балабаны, монгол этәлгесе** Балобан монгольский *Falco cherrug milvipes*

**Себер балабаны, Себер этәлгесе** Балобан сибирский *Falco cherrug saceroides*

**Тибет балабаны, Тибет этәлгесе** Балобан тибетский *Falco cherrug hendersoni*

**Төркестан балабаны, Төркестан этәлгесе** Балобан туркестанский *Falco cherrug coatsi*

**БАЛИМӘР** Медосос

**БАЛИМӘР КОШЛАР** Медосо́совые *Meliphagidae* (семьялык)

**Җырчы балимәр** Медосос певчий *Meliphaga virescens*

**БАЛКҮРСӘТКЕЧ** Медоуказчик

**БАЛКҮРСӘТКЕЧ КОШЛАР** Медоука́зчиковые *Indicatoridae* (семьялык)

**Ак койрыклы балкүрсәткеч** Медоуказчик белохвостый *Melignomon zenkeri*

**Гвинея балкүрсәткече** Медоуказчик гвинейский *Indicator willcocksi*

**Зур балкүрсәткеч** Медоуказчик большой *Indicator indicator*

**Калын томшыклы балкүрсәткеч** Медоуказчик толстоклювый *Indicator conirostris*

**Кече балкүрсәткеч** Медоуказчик малый *Indicator minor*

**Көньяк африка балкүрсәткече** Медоуказчик восточноафриканский *Indicator meliphilus*

**Кыска томшыклы балкүрсәткеч** Медоуказчик короткоклювый *Indicator pumilio*

**Лира койрыклы балкүрсәткеч** Медоуказчик лирохвостый *Melichneutes robustus*

**Малайзия балкүрсәткече** Медоуказчик малайский *Indicator archipelagicus*

**Нәзек томшыклы балкүрсәткеч** Медоуказчик тонкоклювый *Prodotiscus regulus*

**Нәзек томшыклы кәрлә балкүрсәткеч** Медоуказчик тонкоклювый карликовый *Prodotiscus insignis*

**Нәзек томшыклы яшел балкүрсәткеч** Медоуказчик тонкоклювый зелёный *Prodotiscus zambesiae*

**Нәни балкүрсәткеч** Медоуказчик крошечный *Indicator exilis*

**Сары аяклы балкүрсәткеч** Медоуказчик желтоногий *Melignomon eisentrauti*

**Тимгелле балкүрсәткеч** Медоуказчик пятнистый *Indicator maculatus*

**Һинд балкүрсәткече** Медоуказчик индийский *Indicator xanthonotus*

**Чуар башлы балкүрсәткеч** Медоуказчик пестролобый *Indicator variegatus*

**БАНАНАШАР** Бананое́д, тура́ко

**БАНАНАШАР КОШЛАР** Тура́ковые, тура́ко, банано́еды *Musophagidae* (семьялык)

**БАНАНАШАРСЫМАННАР** Туракообра́зные *Musophagiformes* (отряд)

**Ак кикрикле бананашар** Турако белохохлый *Tauraco leucolophus*

**Ак колаклы бананашар** Турако белоухий *Tauraco leucotis*

**Ак корсаклы бананашар** Турако белобрюхий *Tauraco leucolophus*

**Гвинея бананашары** Турако гвинейский *Tauraco persa*

**Зәңгәр аркалы бананашар** Турако синеспинный *Tauraco macrorhynchos*

**Зәңгәр кикрикле бананашар** Турако синехохлый *Tauraco hartlaubi*

**Кара томшыклы бананашар** Турако черноклювый *Tauraco schuetti*

**Кызыл кикрикле бананашар** Турако краснохохлый *Tauraco erythrolophus*

**Озын кикрикле бананашар** Турако длиннохохлый *Tauraco livingstonii*

**Якалы бананашар** Турако шлемоносный *Tauraco corythaix*

**БАРКЫЛДЫК**[р] Деряба *Turdus viscivorus*

**БӘРӘН КАРАГЫ**[р], **бәрәнкарак, сакаллы карчыга, бәрән бөркете, сакалтәй** *к.* карчыга → бәрән карчыгасы

**БӘРӘНКАРАК**[р], **бәрән карагы, сакаллы карчыга, сакалтәй, бәрән бөркете** *к.* карчыга → бәрән карчыгасы

**БЕЗГЕЛДӘК**[р], **дала кошы** Стре́пет Tetrax tetrax

**БЕЗКОЙРЫК**[т], **кылкойрык** Шилохвость *Anas acuta*

**БЕЗТОМШЫК**[т] Шилоклювка *Recurvirostra avosetta*

**Австралия безтомшыгы** Шилоклювка австралийская *Recurvirostra novaehollandiae*

**Америка безтомшыгы** Шилоклювка американская *Recurvirostra americana*

**Анд безтомшыгы** Шилоклювка андская *Recurvirostra andina*

**БИБЕК**[т], **таззит,** *диал.* лыйлыҡ (*тбл.*), лыйлых (*саз.я.*) *к.* тәкәрлек

**БОҖЫР**[т], **чуар көртлек**, *диал.* цел (*туб.-ирт.д.*), чел (*брб.д.*), цил (*тбл., брб.д.*), пыҗыр (*чст.*) Рябчик *Bonasa bonasia*

**БОЛДЫРЫК, дала күгәрчене, чуар күгәрчен** Рябок

**БОЛДЫРЫК КОШЛАР** Рябко́вые *Pteroclididae* (Pteroclidae) (семьялык)

**БОЛДЫРЫКСЫМАННАР** Рябкообра́зные *Pterocliformes* (отряд)

**Ак корсаклы болдырык**[р], **ак корсаклы дала күгәрчене, ак корсаклы чуар күгәрчен** Рябок белобрюхий *Pterocles alchata*

**Буй-буйлы болдырык, буй-буйлы дала күгәрчене, буй-буйлы чуар күгәрчен** Рябок полосатый *Pterocles indicus*

**Җирән бүрекле болдырык, җирән бүрекле дала күгәрчене, җирән бүрекле чуар күгәрчен** Рябок рыжешапочный *Pterocles coronatus*

**Кара битле болдырык, кара битле дала күгәрчене, кара битле чуар күгәрчен** Рябок чернолицый *Pterocles decoratus*

**Кара корсаклы болдырык**[р], **кара корсаклы дала күгәрчене, кара корсаклы чуар күгәрчен** Рябок чернобрюхий *Pterocles orientalis*

**Көньяк Африка болдырыгы, Көньяк Африка дала күгәрчене, Көньяк Африка чуар күгәрчене** Рябок южноафриканский *Pterocles namaqua*

**Мадагаскар болдырыгы**, **Мадагаскар дала күгәрчене, Мадагаскар чуар күгәрчене** Рябок мадагаскарский *Pterocles personatus*

**Сары тамаклы болдырык**, **сары тамаклы дала күгәрчене, сары тамаклы чуар күгәрчен** Рябок желтогорлый *Pterocles gutturalis*

**Сенегал болдырыгы**, **сенегал дала күгәрчене, сенегал чуар күгәрчене** Рябок сенегальский *Pterocles exustus*

**Тимгелле болдырык**, **тимгелле дала күгәрчене, тимгелле чуар күгәрчен** Рябок пятнистый *Pterocles burchelli*

**Төнге болдырык, төнге дала күгәрчене, төнге чуар күгәрчен** Рябок ночной *Pterocles bicinctus*

**БӨРКЕТ**[Т]**,** *диал.* олоҡош (*трх.*), ҡуҡ ҡошо (*бгрс.*), көцөгән (*себ.*), ҡараҡуш (*яүшт., брб.д.*), ҡолаты (*брб.д.*) Беркут *Aquila chrysaetos*

**Аккойрык бөркет**[Р] *к.* каракош → елга каракошы

**Бәрән бөркете**[Р]**, бәрән карагы, бәрәнкарак, сакалтәй, сакаллы карчыга** *к.* карчыга → бәрән карчыгасы

**Үләт бөркете**[Т] *к.* каракош → кабер каракошы

**ДИҢГЕЗ БӨРКЕТЕ** Орлан

**Ак башлы диңгез бөркете**[Р] Орлан белоголовый *Haliaeetus leucocephalus*

**Ак җилкәле диңгез бөркете**[Р] Орлан белоплечий *Haliaeetus pelagicus*

**Ак койрыклы диңгез бөркете**[Т]**, елга каракошы** Орлан-белохвост *Haliaeetus albicilla*

**Грифсыман диңгез бөркете** Орлан грифовый, гриф пальмовый *Gypohierax angolensis*

**Кара диңгез бөркете**[Р] Орлан чёрный *Haliaeetus (pelagicus) niger*

**Озын койрыклы диңгез бөркете**[Р] Орлан-долгохвост *Haliaeetus leucoryphus*

**БӨТЕРЧЕК БАШ**[Т] *к.* ысылдавык

**БҮДӘНӘ**[Т] *к.* бытбылдык

**Австралия бүдәнәсе** *к.* бытбылдык → Австралия бытбылдыгы

**Гади бүдәнә** *к.* бытбылдык → гади бытбылдык

**Кара күкрәкле бүдәнә** *к.* бытбылдык → кара күкрәкле бытбылдык

**Телсез бүдәнә, япон бүдәнәсе** *к.* бытбылдык → телсез бытбылдык, япон бытбылдыгы

**Яңа Зеландия бүдәнәсе** *к.* бытбылдык → Яңа Зеландия бытбылдыгы

**Япон бүдәнәсе, телсез бүдәнә** *к.* бытбылдык → телсез бытбылдык, япон бытбылдыгы

**БҮЗДӘК**[т] Щур *Pinicola enucleator*

**БҮЗТОЙГЫН** *к.* торымтай

**БЫЛБЫЛ I, былбыл кош, гандәлиб** *к.* сандугач

**БЫЛБЫЛ II** Бюльбюль

**БЫЛБЫЛ КОШЛАР** Бюльбю́левые, короткопа́лые дрозды *Pycnonotidae* (семьялык)

**Ак кашлы чын былбыл** Бюльбюль белобровый настоящий *Pycnonotus luteolus*

**Ак күзле чын былбыл** Бюльбюль белоглазый настоящий *Pycnonotus simplex*

**Ак күкрәкле чын былбыл** Бюльбюль бурогрудый настоящий *Pycnonotus xanthorrhous*

**Ак яңаклы чын былбыл** Бюльбюль белощёкий настоящий *Pycnonotus leucogenys*

**Алсу корсаклы чын былбыл** Бюльбюль розовобрюхий настоящий *Pycnonotus cafer*

**Кара башлы чын былбыл** Бюльбюль черноголовый настоящий *Pycnonotus atriceps*

**Кара былбыл** Бюльбюль чёрный *Hypsipetes leucocephalus*

**Кечкенә чын былбыл** Бюльбюль малый настоящий *Pycnonotus erythropthalmos*

**Күзлекле чын былбыл** Бюльбюль очковый настоящий *Pycnonotus nieuwenhuisii*

**Кызыл күзле чын былбыл** Бюльбюль красноглазый настоящий *Pycnonotus brunneus*

**Кызыл яңаклы чын былбыл** Бюльбюль краснощёкий настоящий *Pycnonotus jocosus*

**Кыска бармаклы былбыл**[р] Бюльбюль короткопалый *Microscelis amaurotis*

**Сакаллы чын былбыл** Бюльбюль бородатый настоящий *Pycnonotus barbatus*

**Сары бүрекле чын былбыл** Бюльбюль желтошапочный настоящий *Pycnonotus zeylanicus*

**Сары колаклы чын былбыл** Бюльбюль желтоухий настоящий *Pycnonotus penicillatus*

**Сары корсаклы чын былбыл** Бюльбюль желтобрюхий настоящий *Pycnonotus goiavier*

**Сары тамаклы чын былбыл** Бюльбюль желтогорлый настоящий *Pycnonotus xantholaemus*

**Соры башлы чын былбыл** Бюльбюль сероголовый настоящий *Pycnonotus priocephalus*

**Чуар чын былбыл** Бюльбюль пёстрый настоящий *Pycnonotus striatus*

**БЫЛБЫЛ КОШ, былбыл, гандәлиб** *к.* сандугач

**БЫТБЫЛДЫК**[Т], **бүдәнә** Пéрепел

**Австралия бытбылдыгы, австралия бүдәнәсе** Перепел австралийский *Coturnix pectoralis*

**Гади бытбылдык, гади бүдәнә** Перепел обыкновенный *Coturnix coturnix*

**Кара күкрәкле бытбылдык, кара күкрәкле бүдәнә** Перепел черногрудый *Coturnix coromandelica*

**Телсез бытбылдык, япон бытбылдыгы, телсез бүдәнә, япон бүдәнәсе** Перепел японский, перепел немой Coturnix japonica

**Яңа Зеландия бытбылдыгы, Яңа Зеландия бүдәнәсе** Перепел новозеландский *Coturnix novaezelandiae*

**Япон бытбылдыгы, япон бүдәнәсе, телсез бытбылдык, телсез бүдәнә** *к.* телсез бытбылдык

**БЫТЫЛДАВЫК** Говорушка (акчарлак кошлар семьялыгыннан)

**Кызыл аяклы бытылдавык**[Р] Говорушка красноногая *Rissa brevirostris*

# В

**ВИЛЬСОНИЯ** Вильсония

**Кечкенә вильсония**[Р] Вильсония малая *Wilsonia pusilla*

# Г

**ГАГА, төньяк диңгез үрдәге** Гага

**Гади гага**[Р] *к.* үрдәк → төньяк диңгез үрдәге → гади төньяк диңгез үрдәге

**Кикрикле гага**[Т] *к.* үрдәк → төньяк диңгез үрдәге → кикрикле төньяк диңгез үрдәге

**Күзлекле гага**[Р] *к.* үрдәк → төньяк диңгез үрдәге → күзлекле төньяк диңгез үрдәге

**Себер гагасы**[Р]**, Стеллер гагасы** *к.* үрдәк → төньяк диңгез үрдәге → Стеллер төньяк диңгез үрдәге

**Стеллер гагасы**[Р] *к.* үрдәк → төньяк диңгез үрдәге → Себер төньяк диңгез үрдәге

**ГАГАРА, диңгез казы** Гагара

**ГАГАРА КОШЛАР** Гага́ровые *Gaviidae* (семьялык)

**ГАГА́РАСЫМАННАР** Гагарообра́зные *Gaviiformes* (отряд)

**Ак муенлы гагара**[Р] *к.* каз → диңгез казы → ак муенлы диңгез казы

**Ак томшыклы гагара**[Р] *к.* каз → диңгез казы → ак томшыклы диңгез казы

**Кара бүксәле гагара**[Т] *к.* каз → диңгез казы → кара бүксәле диңгез казы

**Кара томшыклы гагара**[Р] *к.* каз → диңгез казы → кара томшыклы диңгез казы

**Кызыл бүксәле гагара**[Т] *к.* каз → диңгез казы → кызыл бүксәле диңгез казы

**Поляр гагара** *к.* каз → диңгез казы → поляр диңгез казы

**ГАГАРКА, төньяк диңгез кошы** Гагарка

**Канатсыз гагарка** *к.* канатсыз төньяк диңгез кошы

**ГАНДӘЛИБ, былбыл, былбыл кош** *к.* сандугач

**ГА́РПИЯ** Гарпия

**Көньяк Америка гарпиясе** Гарпия южноамериканская *Harpia harpyja*

**ГАРШНЕП**[Т] (уҗым шөлдиләре семьялыгыннан) Гаршнеп *Lymnocryptes minimus*

**ГОАЦИ́Н** Гоацин *Opisthocomus hoazin*

**ГОАЦИН КОШЛАР** Гоаци́новые *Opisthocomidae* (семьялык)

**ГРИФ** Гриф

**АМЕРИКА ГРИФЛАРЫ** Американские грифы *Cathartidae Lafresnaye* (семьялык)

**Ак башлы гриф**Т *к.* тазгара

**Бенгаль грифы**Р Гриф бенгальский *Gyps bengalensis*

**Гриф-ана күркә** Гриф-индейка *Cathartes aura*

**Грифсыман диңгез бөркете** Гриф аальмовый, орлан грифовый

**Затлы гриф** Гриф королевский *Sarcoramphus papa*

**Кар грифы, Һималай грифы** *к.* комай

**Кара гриф**Т Гриф чёрный *Aegypius monachus*

**Һималай грифы, кар грифы** *к.* комай

**ГУАХАРО** Гуахаро, жиряк *Steatornis caripensis*

**ГУАХА́РО КОШЛАР** Гуаха́ро *Steatornithidae* (семьялык)

# Д

**ДАВЫЛ КОШЫ, качу́рка** Качу́рка

**ДАВЫЛ КОШЛАРЫ, качу́ркалар** Качу́рковые *Hydrobatidae* (семьялык)

**Кечкенә давыл кошы**Р Качурка малая *Oceanodroma monorhis*

**Күк давыл кошы**Р Качурка сизая *Oceanodroma furcata*

**Мадейра давыл кошы** Качурка мадейрская *Oceanodroma castro*

**Төньяк давыл кошы**Р Качурка северная *Oceanodroma leucorhoa*

**Туры койрыклы давыл кошы**Р Качурка прямохвостая *Hydrobates pelagicus*

**ДАВЫЛ ХӘБӘРЧЕСЕ** Буреве́стник

**ДАВЫЛ ХӘБӘРЧЕЛӘРЕ** Буреве́стниковые *Procellariidae* (семьялык)

**ДАВЫЛХӘБӘРЧЕСЕСЫМАННАР, көпшәтомшыклылар** Буревестникообра́зные *Procellariiformes* (отряд)

**Аксыл аяклы давыл хәбәрчесе**Р Буревестник бледноногий *Puffinus carneipes*

**Буллер давыл хәбәрчесе**Р Буревестник буллеров *Puffinus bulleri*

**Кечкенә давыл хәбәрчесе** Буревестник малый *Puffinus puffinus*

**Куркусыз давыл хәбәрчесе**[Р] Глупыш *Fulmarus glacialis*

**Левант давыл хәбәрчесе**[Р] Буревестник левантский *Puffinus yelkouan*

**Нәзек томшыклы давыл хәбәрчесе**[Р] Буревестник тонкоклювый *Puffinus tenuirostris*

**Соры давыл хәбәрчесе**[Р] Буревестник серый *Puffinus griseus*

**Чуар битле давыл хәбәрчесе**[Р] Буревестник пестролицый *Calonectris leucomelas*

**Чуар корсаклы зур давыл хәбәрчесе**[Р] Буревестник пестробрюхий большой *Puffinus gravis*

**ДАЛА КОШЫ** *к.* безгелдәк

**ДЖЕК**[Р] *к.* дүдәк → көяз дүдәк

**ДӨЯ КОШЫ** *к.* тәвә кошы

**ДРО́НГО** Дро́нго *Dicrurus*

**ДРО́НГО КОШЛАР** Дро́нговые *Dicruridae* (семьялык)

**Кара дронго**[Р] Дронго чёрный *Dicrurus macrocerus*

**Лира койрыклы дронго**[Р] Дронго лирохвостый *Dicrurus hottentottus*

**ДҮДӘК**[Т]**, дала күркәсе, кыр күркәсе,** *диал.* дуwадақ (*минз., әстр.*) Дрофа *Otis tarda*

**ДҮДӘК КОШЛАР** Дрофи́ные Otididae (семьялык)

**Австралия дүдәге** Дрофа австралийская большая *Ardeotis australis*

**Африка дүдәге** Дрофа африканская большая *Ardeotis kori*

**Кара бүксәле кечкенә дүдәк** Дрофа чернобрюхая малая *Lissotis melanogaster*

**Кара тамаклы кечкенә дүдәк** Дрофа черногорлая малая *Eupodotis vigorsii*

**Кечкенә кара дүдәк** Дрофа чёрная малая *Afrotis afra*

**Кечкенә күк дүдәк** Дрофа голубая малая *Eupodotis caerulescens*

**Кечкенә Сенегал дүдәге** Дрофа сенегальская малая *Eupodotis senegalensis*

**Кечкенә соры дүдәк** Дрофа бурая малая *Eupodotis humilis*

**Көяз дүдәк**[Р]**, джек** Джек, дрофа-красотка *Chlamydotis macqueenii*

**Сакаллы кечкенә дүдәк** Дрофа бородатая малая *Houbaropsis bengalensis*

**Һиндстан дүдәге** Дрофа индийская большая *Ardeotis nigriceps*

# Е

**ЕЛАНАШАР**[Т]**, елан карчыгасы** Змееяд *Circaetus gallicus*

**ЕЛАНМУЕН** Змеешейка

**ЕЛАНМУЕН КОШЛАР** Змеешейковые *Anhingidae* (семьялык)

**Австралия еланмуены** Змеешейка австралийская *Anhinga novaehollandiae*

**Америка еланмуены** Змеешейка американская *Anhinga anhinga*

**Африка еланмуены** Змеешейка африканская *Anhinga rufa*

**Һинд еланмуены** Змеешейка индийская *Anhinga melanogaster*

# Җ

**ҖӘННӘТ КОШЫ, оҗмах кошы** Птица райская

**ҖӘННӘТ КОШЛАРЫ** Райские птицы *Paradisaeidae* (семьялык)

**Зәңгәр җәннәт кошы, зәңгәр оҗмах кошы** Птица райская синяя *Paradisaea rudolphi*

**Зур җәннәт кошы, зур оҗмах кошы** Птица райская большая *Paradisaea apoda*

**Кечкенә җәннәт кошы, кечкенә оҗмах кошы** Птица райская малая *Paradisaea minor*

**Кызыл җәннәт кошы, кызыл оҗмах кошы** Птица райская красная *Paradisaea rubra*

**ҖЫРЧЫ КОШ** Древесница, певун

**Мирт җырчы кошы**[Р] Древесница миртовая (певун миртовый) *Dendroica coronata*

**Елга җырчы кошы**[Р] Певун речной *Seiurus noveboracensis*

**Җирән башлы җырчы кош** Древесница рыжешапочная *Vermivora celata*

# З

**ЗОНОТРИХИЯ** *к.* чыпчык → кәләпүшле чыпчык

**Ак кашлы зонотрихия**[Р] *к.* чыпчык → ак кашлы кәләпүшле чыпчык

**Ак муенлы зонотрихия** *к.* чыпчык → ак муенлы кәләпүшле чыпчык

**Җирән түшле зонотрихия** *к.* чыпчык → җирән түшле кәләпүшле чыпчык

**Кара кашлы зонотрихия**[Р] *к.* чыпчык → кара кашлы кәләпүшле чыпчык

**Себер зонотрихиясе** *к.* чыпчык → себер кәләпүшле чыпчыгы

# И

**ИБИС** И́бис

**ИБИС КОШЛАР** И́бисовые *Threskiornithidae* (семьялык)

**Ашлык ибисы**[Т] *к.* озынтомшык

**Изге ибис**[Р] Ибис священный *Threskiornis aethiopicus*

**Кара башлы ибис**[Р] Ибис черноголовый *Threskiornis melanocephalus*

**Кызыл аяклы ибис**[Р] Ибис красноногий *Nipponia nippon*

**ИГӘҮБОРЫН** Крохаль

**Зур игәүборын**[Т] Крохаль большой *Mergus merganser*

**Кабырчыклы игәүборын**[Р], **тәңкәле игәүборын** Крохаль чешуйчатый *Mergus squamatus*

**Озын томшыклы игәүборын**[Т] Крохаль длинноносый *Mergus serrator*

**Тәңкәле игәүборын**[Р] *к.* кабырчыклы игәүборын

**ИМӘНБОРЫН** Дубонос

**Гади имәнборын**[Р] Дубонос обыкновенный *Coccothraustes coccothraustes*

**Зур кара башлы имәнборын**[Р] Дубонос черноголовый большой *Eophona personata*

**Капюшонлы имәнборын** Дубонос капюшонный *Coccothraustes abeillei*

**Кечкенә кара башлы имәнборын**Р Дубонос черноголовый малый *Eophona migratoria*

**Сары имәнборын** Дубонос вечерний *Coccothraustes vespertinus*

**Урман имәнборыны**Р Дубонос арчёвый *Mycerobas carnipes*

**ИПАТКА** *к.* диңгез тутые → Тын океан диңгез тутые

**ИШКӘГАЯК** О́луша

**ИШКӘГАЯК КОШЛАР** О́лушевые *Sulidae* (семьялык)

**Битлекле ишкәгаяк** Олуша масковая, олуша голуболицая *Sula dactylatra*

**Көрән ишкәгаяк**Р Олуша бурая *Sula leucogaster*

**Күк ярылы ишкәгаяк** Олуша голубоногая *Sula nebouxii*

**Кызыл ярылы ишкәгаяк** Р Олуша красноногая *Sula sula*

**Перу ишкәгаягы** Олуша перуанская *Sula variegata*

**Себер ишкәгаягы**Р Олуша северная *Morus bassanus*

**ИШКӘККАНАТ** Чи́стик *Cepphus grylle*

**ИШКӘККАНАТ КОШЛАР** Чи́стиковые *Alcidae* (семьялык)

**Ак бүксәле ишкәкканат**Р *к.* акбүксә

**Күзлекле ишкәкканат**Р Чистик очковый *Cepphus carbo*

**Тын океан ишкәкканаты**Р Чистик тихоокеанский *Cepphus columba*

# Й

**ЙӨГЕРЕККОШ**Р**, йөгерек сакаллы шөлди** Бегунок *Cursorius cursor*

# К

**КА́ГУ** Ка́гу *Rhynochetos jubatus*

**КА́ГУ КОШЛАР** Ка́гу *Rhynochetos* (семьялык)

**КАЗ** Гусь

**КАЗСЫМАННАР** Гусеобра́зные *Anseriformes* (отряд)

**Ак башлы каз**Т**, акбаш, су тавыгы** *к.* кашкалак

**Ак каз**Р Гусь белый *Anser caerulescens (Chen caerulescens)*

**Ак маңгайлы каз**Т Гусь белолобый *Anser albifrons*

**Ак муенлы каз**Р *к.* акмуен

**Коры борынлы каз**^Р^ *к.* корыборын
**Кыска томшыклы ындыр казы**^Р^ Гуменник короткоклювый *Anser brachyrhynchus*
**Рос казы**^Р^ Гусь Росса *Anser rossii*
**Соры каз**^Т^ Гусь серый *Anser anser*
**Тау казы**^Р^ Гусь горный *Anser indicus*
**Чыелдык каз**^Т^ Пискулька *Anser erythropus*
**Ындыр казы**^Т^ Гуменник *Anser fabalis*

**ДИҢГЕЗ КАЗЫ, гагара** Гагара

**ДИҢГЕЗ КАЗЛАРЫ, гагара кошлар** Гага́ровые *Gaviidae* (семьялык)

**Ак муенлы диңгез казы**^Р^**, ак муенлы гагара** Гагара белошейная *Gavia pacifica*

**Ак томшыклы диңгез казы**^Р^**, ак томшыклы гагара** Гагара белоклювая *Gavia adamsii*

**Кара бүксәле диңгез казы**^Т^**, кара бүксәле гагара** Гагара чернозобая *Gavia arctica*

**Кара томшыклы диңгез казы**^Р^**, кара томшыклы гагара** Гагара черноклювая *Gavia immer*

**Кызыл бүксәле диңгез казы**^Т^**, кызыл бүксәле гагара** Гагара краснозобая *Gavia stellata*

**КЫЗЫЛКАЗ**^Т^**, фламинго** Фламинго

**КЫЗЫЛКАЗЛАР** Флами́нговые *Phoenicopteridae* (семьялык)

**КЫЗЫЛКАЗСЫМАННАР** Фламингообра́зные *Phoenicopteriformes* (отряд)

**Алсу кызылказ**^Р^**, алсу фламинго** Фламинго розовый, фламинго обыкновенный *Phoenicopterus roseus*

**ТУНДРА КАЗЫ, казарка** Казарка

**Ак яңаклы тундра казы**^Т^**, ак яңаклы казарка** Казарка белощёкая *Branta leucopsis*

**Америка тундра казы, Америка казаркасы** Казарка американская *Branta bernicla nigricans*

**Чернеть** Карагай үрдәк, карагай 64
**Чернеть американская, нырок американский красноголовый** Америка карагай үрдәге, Америка карагае 64
**Чернеть морская** Диңгез карагай үрдәге, диңгез карагае 64

**Чернеть морская малая** Кечкенә карагай үрдәк, кечкенә карагай 64
**Чернеть хохлатая** Бүрекле карагай үрдәк, бүрекле карагай 64
**Чернозобик** Кара бүксәле чуллык 70
**Черныш** Кара шөлди 85
**Чечевица** Ясмык чыпчыгы 84
**Чечевица арчовая**, **чечевица розовая малая** Алсу ясмык чыпчыгы, арча ясмык чыпчыгы 84
**Чечевица большая** Зур ясмык чыпчыгы 84
**Чечевица длиннохвостая**, **урагус** Озын койрыклы ясмык чыпчыгы, урагус 84
**Чечевица обыкновенная** Гади ясмык чыпчыгы 84
**Чечевица розовая малая**, **чечевица арчовая** Алсу ясмык чыпчыгы, арча ясмык чыпчыгы 84
**Чечевица сибирская** Себер ясмык чыпчыгы 84
**Чечевичник краснокрылый** Кызыл канатлы ясмык чыпчыгы 84
**Чечётка** Чи-чи чыпчык 82
**Чечётка горная** Таулык чи-чи чыпчыгы 82
**Чечётка обыкновенная** Гади чи-чи чыпчык 82
**Чечётка пепельная** Көлсыман чи-чи чыпчык 82
**Чибис**, **пигалица** Тәкәрлек, бибек, таззит 57
**Чибис серый** Соры тәкәрлек 57
**Чибис украшенный** Бизәкле тәкәрлек 57
**Чиж** Сары чыпчык 73
**Чирок** Чүрәкәй үрдәк 65
**Чирок зеленокрылый** Яшел канатлы чүрәкәй 71
**Чирок мраморный** Мәрмәр чүрәкәй үрдәк 65
**Чирок-свистунок** Сыбызгы чүрәкәй, сызгырак чүрәкәй, алмабаш, алмабаш чүрәкәй 71
**Чирок-трескунок** Чытырдавык чүрәкәй 71
**Чистик** Ишкәкканат 33
**Чистик очковый** Күзлекле ишкәкканат 33
**Чистик тихоокеанский** Тын океан ишкәкканаты 33
**Чомга**, **поганка** Чумга 71
**Шилоклювка** Безтомшык 24
**Шилоклювка австралийская** Австралия безтомшыгы 24
**Шилоклювка американская** Америка безтомшыгы 24

**Шилоклювка андская** Анд безтомшыгы 24
**Шилохвость** Безкойрык, кылкойрык 24
**Широконоска** Киңборын 41
**Широкорот** Киңавыз 41
**Широкорот африканский** Африка киңавызы 41
**Широкорот восточный** Көньяк киңавызы 37
**Широкорот синегорлый** Зәңгәр тамаклы киңавыз 41
**Щегол** Купшыл, купшы чыпчык, көяз тургай 43
**Щегол седоголовый** Соры башлы купшыл, соры башлы купшы чыпчык, соры башлы көяз тургай 43
**Щегол черноголовый** Кара башлы купшыл, кара башлы купшы чыпчык, кара башлы көяз тургай 43
**Щёголь** Көяз чуаркош 70
**Щур** Бүздәк 26
**Щурка** Корташар 41
**Щурка белогорлая** Ак тамаклы корташар 41
**Щурка белолобая** Ак маңгайлы корташар 41
**Щурка Бёмова** Бём корташары 41
**Щурка буроголовая** Көрән башлы корташар 42
**Щурка жёлто-зеленая** Саргылт-яшел корташар 42
**Щурка зелёная** Яшел корташар 42
**Щурка зелёная малая** Кечкенә яшел корташар 42
**Щурка золотистая** Саргылт корташар, алтын карга, сары карга 42
**Щурка карликовая** Кәрлә корташар 42
**Щурка краснобородая ночная** Кызыл сакаллы төнге корташар 42
**Щурка красногорлая** Кызыл тамаклы корташар 42
**Щурка ласточкохвостая** Карлыгач койрыклы корташар 42
**Щурка малайская** Малайзия корташары 42
**Щурка ошейниковая** Муенчаклы корташар 42
**Щурка радужная** Төсле корташар 42
**Щурка розовая** Алсу корташар 41
**Щурка синебородая ночная** Күк сакаллы төнге корташар 42
**Щурка синеголовая** Зәңгәр башлы корташар 42
**Щурка синегрудая** Зәңгәр түшле корташар 42
**Щурка синехвостая** Зәңгәр койрыклы корташар 42
**Щурка черноголовая** Кара башлы корташар 42
**Щурка чёрная** Кара корташар 42

**Эму** Австралия кәсвәре, эму 40, 88
**Юнко** Юнко 88
**Юнко орегонский** Орегон юнко кошы 88
**Юнко серый** Соры юнко 88
**Юрок**, **вьюрок** Тау чыпчыгы 80
**Ягнятник**, **бородач** Бәрән карагы, бәрәнкарак, сакаллы карчыга, бәрән бөркете, сакалтәй, бәрән карчыгасы 88
**Якамара** Ялтыравык чыпчык, якамара 90
**Якамара зеленая** Яшел ялтыравык чыпчык, яшел якамара 73
**Якана** Якана 90
**Якана африканская** Африка яканасы 90
**Якана индийская** Һинд яканасы 90
**Якана мадагаскарская** Мадагаскар яканасы 90
**Якана малая** Кечкенә якана 90
**Якана фазанохвостая** Кыргавыл койрыклы якана 90
**Ястреб** Карчыга 38
**Ястреб коротконогий** Кыска аяклы карчыга 38
**Ястреб короткопалый** Кыска бармаклы карчыга 38

## ТАТАР ДИАЛЕКТЛАРЫНДА
## ҺӘМ СӨЙЛӘМ ТЕЛЕНДӘ КУЛЛАНЫЛГАН
## ОРНИТОНИМНАР

**Абалак** (*себ.*) – сова
**Ағала** (*себ.*) – один из видов уток
**Ағош** (*брб.д.*) – лебедь
**Аққу** (*әстр.*), ақ қуу (*твр.*) – лебедь
**Ақсырдақ** (*злт.*) – чайка
**Ала туба** (*перм.*) – голубь
**Әтәз** (*каз.ар.*) – петух
**Әтәс** (*минз., глз., нокр.*) – петух
**Әтиц** (*клм.*) – петух
**Әцәт** (*срг.*) – петух
**Әчәт** (*чст., срг., мәл., карс.*) – петух
**Бабалаш** (*перм.*) – филин
**Балцарға** (*тбл.*) – сыч воробьиный
**Барабикә** (*том.д.*) – воробей
**Барқылдақ** (*перм.*) – дрозд, (*тпк.*) – один из видов утки
**Бәрәбишкә** (*том.д.*) – воробей
**Бикцәргә** (*төм.*) – сыч воробьиный
**Бистурғай** (*кмшл.*) – дрозд, дрозд-рябинник
**Буйтайақ** (*твр.*) – один из видов ястреба
**Бүзтурғай** (*әстр.*) – воробей
**Җабалақ** (*урт.д.*) – сова
**Җиләк чыпчык** (*перм.*) – крапивник
**Йағалбай** (*твр.*) – кобчик
**Йапалақ** (*кргл.*) – сова
**Йапқолақ** (*брб.д.*) – сова
**Йарйарлыйқ** (*твр.*) – филин
**Ихахай җабалақ** (*дәб.*) – филин
**Кара йабалак** (*нокр.*) – неясыть обыкновенная, неясыть серая
**Карабай (карабай тургай)** – черный воробей

**Кәгәwец** (*брб.д.*) – кулик
**Керәк** – вид диких уток
**Кигәвеч**, **кигәвец** – вид дикой утки (селезня)
**Киклек**, **кәклек** – горная куропатка
**Көгөлде** (*твр.*) – кулик
**Көгөндә** (*брб.д.*) – кулик
**Көелде** (*твр.*) – кулик
**Көелте** – кулик
**Көстийә** (трх.) – один из видов маленьких лесных птичек
**Көцөгән** (*себ.*) – орёл
**Күкәнәш** – вид птицы наподобие синицы
**Күцкер** (*төм.*) – кулик
**Кукумийау** (*кузн.*) – филин
**Кукымәү** (*тмн.*) – филин
**Қағар (**_туб.-ирт._) – один из видов диких уток
**Қагау** (*перм.*) – ястреб
**Қағау** (*минз., брб.д.*) – коршун
**Қазыйақ** (*минз.*) – чайка
**Қара йабалақ** (*нокр.*) – неясыть бородатая
**Қарабылқы** (*том.д.*) – филин
**Қарақуш** (*яүшт., брб.д.*) – орёл
**Қашқалақ** (*брб.д.*) гагара; (себ.) – один из видов диких уток
**Қәлмәргән** (*туб.-ирт.д.*) – чайка
**Қолаты** (*брб.д.*) – орёл
**Қуғуч** (*брб.д.*) – кулик
**Қуйан йабалақ** (*перм.*) – сова белая
**Қуқ қошо** (*бгрс.*) – орёл
**Қуртай** (*тара.*) – цапля
**Қуу** (*твр.*) – лебедь
**Қыр қәҗәсе** (*каз.ар.-крш.*) – бекас
**Қысмыц** (*брб.д.*) – кулик
**Лыйлық** (*тбл.*) – чибис, пигалица
**Лыйлых** (*саз.я.*) – чибис, пигалица
**Майған** (*тара., том.д.*) – один из видов утки
**Мачы баш(ы)** (*лмб.*) – филин
**Олоқош** (*трх.*) – орёл
**Өгө** (*төм., саз.я.*) – филин
**Өкө йабалагы** (*тпк.*) – филин
**Өкө йабалақ** (*перм.*) – филин

**Өкө қарчыга** (*перм.*) – филин
**Өхө** (*саз. я.*) – филин
**Пақцар** (*төм., тбл.*) – дрозд
**Пақцарғы** (*тбл.*) – сыч воробьиный
**Палықцы** (*төм., тбл., брб.д.*) – баклан
**Палыхцы** (саз.я.). – один из видов уток
**Пархылдақ** (*перм.*) – дрозд
**Песәй башлы йабалақ** (*минз.*) – филин
**Пурлы үртәх** (*саз.я.*) – один из видов уток
**Пыҗыр** (*чст.*) – рябчик
**Силәзән** (*злт., срг.*) – селезень
**Тастилгән** – коршун, вид коршуна
**Тәллеторна**, **тиллеторна** – вид птицы, похожей на журавля (**тәллтәвеч)**
**Тилгәнтас** (*тбл.*) – коршун
**Тилгәткән** (*тара.*) – коршун
**Тиресаяк** – чомга
**Тойгын** – белый сокол
**Төнләце** (*төм.*) – филин
**Туқмақбаш** (*перм.*) – вид ястреба
**Туба** (*минз.*) – голубь
**Турач** – турач (птица семейства фазановых)
**Турғай** (*перм., тпк., эчк., әстр., себ.*) – воробей
**Тургай** (*стрл.*) – воробей
**Үгү** (*тбл.*) – филин
**Үтәгән** – крохаль, утка-свистунка
**Урман пархылдақ** (*перм.*) – дрозд
**Филим** (*нокр.*) – филин
**Хәүле** (*кргл.*) – цапля
**Цәпце** (*туб.-ирт.д.*) – цапля
**Цел** (*туб.-ирт.д.*) – рябчик
**Целе** (*саз.я.*) – цапля
**Цил** (*тбл., брб.д.*) – рябчик
**Цөрәгәй** (*төм., тбл., саз.я.*) – утка-нырок
**Цөрәгәй таwық** (*тбл.*) – утка-нырок
**Цөрәкәй** (*саз.я.*) – утка-нырок
**Цумға** (*туб.-ирт.д.*) – гоголь
**Цумғы** (*саз я..*) – гоголь
**Чагалтай**, **чагалмай** – вид чайки

**Чел** (*брб.д.*) – рябчик
**Чийәк йабалақ** (*мам.*) – один из видов совы
**Чумға** (*саз я.*) – гоголь
**Чумғақ** (*каз.ар.-лш.*) – нырок
**Чупай йабалақ** (*трбс.*) – филин
**Чыпчық җабалақ** (*лш.*) – сыч воробьиный
**Этәлә**, **этәлә каз** – вид степного гуся
**Эшләки, эшләкәй** – синица

# КОШЛАР БЕЛӘН БӘЙЛЕ СЫНАМЫШЛАР, МӘКАЛЬ-ӘЙТЕМНӘР, КАНАТЛЫ СҮЗЛӘР

## СЫНАМЫШЛАР

### Һава торышын, ел фасылларын сынау

Аерыкойрыклар түбән генә очсалар, явым булыр.

Аккош иртә килсә, яз начар булыр, озак торыр.

Аккош яз көне иртә күренсә, салкын булыр, кар тиз китмәс.

Акчарлак килгәч, елгаларда боз тиз кузгалыр.

Ала карга агач башына кунса – яз тиз, җиңел килер, җиргә кунса – озак килер.

Апрель аенда торна кычкырса, ел яхшы килә.

Апрельнең алтысында торна кычкырса, ел яхшы килә.

Әгәр Питрауга бер атна кала күке кычкырудан туктамаса, көз тиз булыр, әмма Питрау үткәч тә бер атна кычкырса, озак булыр.

Әгәр тавыклар яз көнендә куначадан иртә төшсәләр – җәй начар булыр, әгәр соң төшсәләр – җәй яхшы булыр.

Әгәр тәкәрлек һәм бытбылдык биек җиргә оя ясаса, җәй яңгырлы булыр.

Әгәр торна кышларга тиз китсә, кыш суык һәм озак булыр.

Әгәр торналар берәмләп-берәмләп килсәләр, җәй яхшы булыр.

Әтәч каралты арасына кереп кычкырса – һава бозылыр, югары урынга менеп кычкырса – аяз булыр.

Әтәч кичтән кычкырса – җылыта.

Беренче мартка кадәр кара карга күренсә, кар тиз китәр.

Болыт килгәндә әтәч кычкырса – көн аязырга.

Бытбылдык Питрау алдыннан сузып кычкырса, көз озын булыр.

Вакытсыз әтәч кычкыру – явымга. Кыш көне вакытсыз кычкырса, җепшек булыр.

Җәүзә көнне сандугачлар сайрый башлый, Питрау кергәч туктый.

Иртә белән урманда карга агач башына утырып кычкырса, һава бозылыр.

Каз авызын шакылдатса, рашкы явар.

Каз аягын күтәреп торса, салкын була.

Каз башын канат астына тыкса, салкын була.

Каз коры җирдә «коенса» – салкын булырга.

Каз тешен шакылдатса, салкын булыр.

Каз югарыдан очса, яз көне су күп булыр.

Казлар суда чумып-чумып уйнаса, яңгыр була.

Кара карга килгәч, бер айдан кар китәр.

Кара карга килгәч җиргә төшсә – яз кыска килер, ояга төшсә – яз озын килер.

Кара каргалар яки чәүкәләр югары менеп, җиргә кадалып төшсәләр, яңгыр булыр.

Карга, чәүкә түбәннән очса, кар ява.

Карга җилгә каршы утырып кычкырса, яңгыр булыр.

Каргалар кычкырып кайсы якка карасалар, шул яктан яңгыр көт.

Карлыгач иртә килсә, көннәр тиз матурланыр.

Карлыгач кышларга иртә китсә, кыш суык, озак булыр.

Карлыгач уйнап йөрсә, шул көн яңгыр явар.

Карлыгачлар коенса, яңгыр булыр.

Кечкенә кошлар һавага биек күтәрелсә, аяз булыр.

Кошлар кар өстенә төшсә, көн җылыта.

Кошлар югары очып уйнасалар, җил буласына.

Кояш баегач әтәч кычкырса, көн аяз булыр.

Көз көне кошлар түбән очса – кыш салкын, югары очса – кыш җылы килә.

Кыйгыр яңгыр алдыннан кычкыра.

Кыр казлары иртә китсә, кыш иртә килә.

Кыш аязырга булса, кошлар борыны белән үзен-үзе чукып койрыгын кашыр.

Күке бака тавышы чыгарып кычкырса, яңгыр булыр.

Күке кычкырса, су җылына.

Күке күкелдәмичә май җылытмый.

Март башында җирдә тавык эчәрлек су булса, яз яхшы килә.

Мәче башлы ябалак кычкырса, суыклар башланыр.

Өй тирәсендә карлыгач очып йөрсә, һава начар булыр.

Өйлә вакытында әтәч кычкырса, көн алышына.

Питраудан соң сандугачлар да сайрамый, сайраса да, «Галәви, Галәви» дип кенә кычкыра, ди.

Питраудан өч-дүрт көн соң сандугач сайраса, Питраудан дүрт атна яки биш атнадан соңрак көз башланыр.

Сентябрь башларында тавыклар каурыйларын коя башласалар, ел суык була.

Сиртмәкойрык килеп бозга кунгач, боз китәр.

Тавык бер аяк белән басып торса, өй түбәсенә очып менсә – суык булыр.

Тавыклар бер якка карап кына утырсалар, аязлана.

Тавыклар озак йокламаса, яңгыр була.

Тартай, бүдәнә кычкырса, яңгыр булыр.

Тилгән кычкырса, озак аяз булыр.

Торна биесә, һава җылыныр.

Торна иртә килсә, яз озак тормас, тиз җылытыр.

Торналар бик кычкырышса, яңгыр булыр.

Тургай килгәч – тугыз көнлек, сыерчык килгәч сигез көнлек кар кала.

Тургай түбәннән очса, көз кыска булыр.

Тургайлар күмәкләп бер урыннан бер урынга очып йөрсәләр, көчле җил булачак.

Үрдәк коенса, салкын булыр.

Үрдәкләр суда кагынып кычкырсалар – яңгырга. Әгәр суда шыпырт кына торсалар – яшен булыр.

Һава бозылырга булса, күгәрченнәр бик гөрләшә.

Һава яхшы чакта торналар кычкырышса, һава бозылыр.

Чәүкәләр көтүе белән очса һәм җиргә кунса, очканда каты чуылдашсалар, яңгыр яки давыл көт.

Чебешләр бер җиргә җыелсалар, яңгыр була.

Чыпчыклар агач очына кунсалар – көн салкын була, түбән ботакларына кунсалар – җил чыга.

Чыпчыклар чыркылдашса, көн җылыта.

Язын сыерчык иртә килсә, көннәр җылы булыр.

Яңгыр алдыннан күркәләр җирдә аунар, кагыныр.

Яңгыр буласы булса, карлыгач бик түбәнтен очар.

Яңгыр буласы, көн бозыласы булса, казлар, үрдәкләр су өстендә җәяү йөгерер.

Яңгыр я кар яуганда кошлар очса, явым-төшем туктамас.

Яңгыр яуганда әтәч кычкырса – яңгыр туктауга.

## Ашлык, яшелчә, җиләк-җимеш уңышы ничек булачагын сынау

Әгәр карга ябыгып килсә, ашлык уңар.

Әгәр тавыкның беренче йомыркасы бер әчмуха килсә, уңыш яхшы була.

Әтәчләр өзлексез кычкырсалар, ашлык уңар.

Бытбылдык рәттән күп кычкырса, борай уңар.

Бытбылдык кычкырган елны иген була, тартар кычкырса – иген булмый.

Бытбылдык яз көне тартардан элек кычкырса – ашлык яхшы булыр; тартар бытбылдыктан элек кычкырса – ашлык начар булыр.

Кара каргалар ояга утырса, өч атнадан чәчүгә чыгарга кирәк.

Каргалар тоташ йөрсә, ашлык уңар.

Карлыгач килсә, борчак чәчәргә кирәк.

Корт ашаган урынга арпа яки карабодай чәч.

Кыр казлары яз көне биектән очсалар – сабан ашлыгы бик уңар, түбәнтен очсалар – ашлык гадәттәгечә булыр.

Кырмыска түмгәгенә таяк тыккач, кырмыскалар таяк башына кадәр менсәләр – җитен озын булыр.

Кәккүк яз көне агачлар яфрак яргач та кычкырса, ачлык булыр.

Күк күкрәүдән элек торна кычкырса, туклык булыр.

Озынборыннар яздан ук югары болгансалар, солы бик уңар.

Суда бака кычкыра башлаганда сабанга чык.

Сыерчык бала чыгарганда карабодай чәч.

Сыерчыклар иртә килсә – сабан ашлык уңа, соң килсә – арыш уңа.

Сыерчыктан алда тургай килсә, туклык була.

Тавыклар оя басарга соң утырып, иртә торсалар – ачлык булыр.

Тавыкның беренче өч йомыркасын үлчәп, беренче йомыркасы авыр булса – иртә чәчкән, икенчесе авыр булса – уртада чәчкән, өченчесе авыр булса – соңгы чәчкән иген уңа.

Тартай күп булса, печән күп булыр.

Торна биегән җирдә иген булмый.

Торна кар барында килсә, тары, борчак уңар.
Тургай сайрый башласа, сабанга чык.
Үрдәкләр түбән очса, тары уңар.
Чыпчыклар басуга көтүе белән төшсә, арыш чәчәргә вакыт.

## МӘКАЛЬ-ӘЙТЕМНӘР, КАНАТЛЫ СҮЗЛӘР

### АКЧАРЛАК

Акчарлак килми яз булмый.
Акчарлак суда булыр.

### АККОШ

Аккош аягына су йокмас.
Аккош күрсәң – атып ал, былбыл күрсәң – сатып ал.
Аккош очар күл күреп, былбыл очар гөл күреп.
Аккош ялгыз яшәмәс.
Аккош, ярыннан калса, үзен таш кыяга орыр имеш.
Аккош һәр күлгә төшмәс.

### ӘТӘЛГЕ

Әтәлге, мактанса, «тычкан тоттым!» дияр.
Әтәлгене куй, карчыганы чөй.

### БАЙГЫШ

Байгыш байгышны яклар.
Байгыш та үз баласына лачын дип исем кушкан.
Байгыш чыпчык аулар.
Байгыштан байгыш туар.
Башыңа кунса, байгыш та сәмруг булыр.

### БӨРКЕТ

Азга бөркет кунган, күпкә дуңгыз туйган.
Ата бөркет аерым очар, бала бөркет парлап очар.
Бөркет батырлык хакына түгел, тамак хакына корбан эзли.
Бөркет бәрән ауласа – өлгесе, тычкан ауласа – көлкесе.
Бөркет биектән курыкмас.
Бөркет, картайса, тычкан аулар.
Бөркетнең канаты очканда ныгый.

Бөркетнең оясы биек ташта булыр.

Кошларны җыйсаң, бөркет җый, кышкы туның төлке итәр.

## БЫТБЫЛДЫК (БҮДӘНӘ)

Бер ел бүдәнә симерә, икенче елны тартай симерә.

Бүдәнә симереп батман булмас.

Бүдәнәнең унике пот мае бар.

Бүрәнәгә басты бүдәнә, бүдәнәне басты бүрәнә: бүрәнә дә гаепле, бүдәнә дә гаепле.

Бытбылдык үз атын үзе сатар.

Бытбылдыктан бер пот май чыккан да, аның да үзенә күрә бер үлчәве булган, ди.

Бытбылдыкның төне юк, һәрвакытта: «бытбылдык».

Җәйгә чыкса, бытбылдык күкәй сала, тартайның көчәнеп арты тала.

Һәр бытбылдык үз сазын мактый.

## КАРАКОШ

Каракош басып ашар.

Каракош та кояштан ары күтәрелә алмый.

Каракошка ут тигән, каерылып караса – үз йоны.

Каракошның күзләре үткен булса да, тамыры черегән агачка оя ясый.

## КАРГА

Аксак карга башкалардан элек очар.

Ала карга – азанчы, кара карга – казанчы.

Ала карга алдан кычкырып харап итә, калҗасын төлке алып китә.

Ала карга гына ата-анасына ошый.

Ала карга көз көне бер авыл җир очып бара икән дә, «ерак киттем бугай» дип, кире әйләнеп кайта, ди.

Ала каргада аласың булсын, курыкма.

Ала каргада аласың булсын, кыш кайтмаса, яз кайтыр.

Ала каргадай алдан олы кычкыру.

Асыл буяуга төшкән белән карга каргалыктан чыкмас.

Әҗәле җиткән карга бөркет белән уйный.

Балалы каргадан чүп тә калмый.

Безгә дә карга утырыр әле.

Бер карга кыш ясамас.

Бер карга туярлык ите юк.

Былтыр үлгән карга быел сасыган.

Идел каргасы – Идел ибенә, Җаек каргасы Җаек җаена очар.

Ике карга бер-берсенең каралыгына гаҗәпләнгән.

Ике карга талашса, бер козгынга җим төшәр.

Иртә торган карга ашап туя, соң торганы борынын кыра.

Иртә торган карганың авызы-борыны май була.

Йөз каргага бер таш җитә.

Каз кебек кычкырамын дип, карганың арты ертылган, ди.

Каз урынына карга.

Казынган карга кар астыннан калҗа тапкан, казынмаган – кар астында катып үлгән.

«Кар» дисәң, каргага барып тия, «тор» дисәң – торнага.

Кара карга гына картаймый.

Кара карганы сабынлап юсаң да агармас.

Карга «кар-кар» дигәндә, тартар да «тар-тар» ди.

Карга баласы төп чукыр.

Карга баласына: «Бер чукы да, биш артыңа кара», – дип әйтә, ди.

Карга баласының авызын таш белән томаламасаң, карылдаудан туктамас.

Карга белән кунышсаң, борының тизәктән котылмас.

Карга булып тугач каргылдарга гына кала.

Карга җимгә төшмәс борын.

Карга ит ашаса да кычкыра, тизәк ашаса да кычкыра.

Карга казганыр, тилгән кинәнер.

Карга кайда кычкырса, оясы шунда була.

Карга каңгылдап каз булмас.

Карга кар теләсә, яңгыр явар.

Карга карга берлә очар.

Карга карганың күзен чыгармас (чукымас).

Карга карганып ышандыра.

Карга каргаса – үз башына.

Карга кардан курыкмас, көртлек көрттән курыкмас.

Карга карылдаса – кышны чакырыр, каз каңгылдаса – язны чакырыр.

Карга карылдау белән генә җил килмәс.

Карга килсә, кар китәр.

Карга кунса – көтүе белән.

Карга күзе төшкән орлык шытмас.

Карга күке баласын күпме ашатса да, «кәккүк» дип кычкырыр.

Карга кычкыру белән яңгыр килмәс.

Карга мең карылдаса да, яз булмас.

Карга мие эчкән.

Карга өч йөз ел яшәсә дә, карга булып үләр.

Карга теләге белән кар яумый.

Карга үз аты белән кычкыра.

Карга үзен кош санар.

Карга үзенең баласын «аппагым» дип сөяр, керпе үзенең баласын «йомшагым» дип сөяр.

Карга үзенең баласына: «Зариф зирәктәй туган», – дип әйтә, ди.

Карга үстерсәң, күзең чукыр.

Карга чебеш ала, тавык очынып кала.

Карга, казга охшыйм дип, ботын каерган.

Карга, ни хәтле канатын җыеп очса да, карчыга булмас.

Карга, ни хәтле югары күтәрелмәсен, барыбер үләксәгә кунар.

Карга, саескан йөрүен йөрим, дип, үз йөрүен оныткан имеш.

Карга, тутый кош йөрешен йөреп, үз йөрешен оныткан.

Карга юлбашчы булса, үләксәгә алып барыр.

Каргага аттым – бозауга тиде.

Каргадан карга туа, козгыннан козгын туа.

Каргадан карчыга тумас.

Карганы бал белән сыйласаң да, тизәк чукымый туймас.

Карганы каргап биздерә алмассың.

Карганы патша иткәннәр дә, «кар-р» дип кычкыра белмәгән барлык кошларның да күзен чукыган, ди.

Карганы читлеккә япмыйлар.

Карганыкы көн дә каркылдау.

Карганың «карык» дигәне үзенә ямь.

Карганың бар дөньясы агач башында, балалары – тирәдә.

Карганың бер күзе укта, бер күзе чүптә.

Куркакланган карга куләгәгә кунмас.

Сандугач сайрый дип, карга да кычкырган.

Тавис каурыйлары таккан карга.

Тизәк ашаган карга да кыш чыга, бодай ашаган күгәрчен дә кыш чыга.

Турыдан карга гына оча.

Тутый кош каурыена төренгән карга.

Үзең карга булгач, кая барсаң да кара йомырка саласың.

Үзәге янган карга таш чукыр.

Чукыган карга ач калмас.

Ялгыз карга каркылдап яу китермәс.

Ят карганың тавышы тансык булыр.

## КАРЛЫГАЧ

Бер карлыгач килеп яз булмый, бер саескан килеп кыш булмый.

Карлыгач – йортка, сандугач бакчага кунар.

Карлыгач сандугачка иярә алмас.

Карлыгачның койрыгы җәпле, еланның – теле.

Карлыгачтан көнне сора, сандугачтан төнне сора.

Очканда карлыгач узар, сайраганда сандугач узар.

## КАРЧЫГА

Бер чебеш алган карчыга икенчесенә янә кайтыр.

Ике карчыга сугышкан, киекчегә йон файда.

Карчыга авызыннан ит кире чыкмый.

Карчыга каргадан курыкмас.

Карчыга күгәрчен белән дус түгел.

Карчыга очуыннан танулы.

Күрше авылның карчыгасы – үз авылыңның каргасы.

Очарга ирек бирмәсәң, яхшы карчыга да берни тотмас.

Үлгән карчыгадан тере саескан артык.

Чит илнең карчыгасын үз илеңнең каргасы талый.

Чөймәгә бирсәң, карчыга бир – канҗыгаңны буш итмәс.

## КЕНӘРИ

Кенәри үзе читлектә, күңеле иректә.

## КОЗГЫН

Козгын баласы анасыннан да узган.

Козгын карганы «кара» дип хурлаган.

Козгын каркылдаган саен кауга какмыйлар.

Козгын юл башларга оста булыр.
Козгын яу башлар, яуга карга иярер.
Козгынга да үз баласы былбыл күренер.
Козгынныкы – агач башында, карганыкы – уртак.
Үләксә исен козгын алдан сизәр.

### КӨЕЛДЕ, КӨЕЛТЕ

Һәрбер көелте үз сазлыгын мактый.

### КӨРТЛЕК

Көртлек, кар астына башын яшергән белән, артын күрмиләр дип уйлый.
Көртлек әйткән ди: «Көрткә чумсам да, кышны чыгармын».
Озанлы (көртлекле) җир – үләнле җир.
Тозагын кормас борын көртлеген ашый башлама.
Үз туенда көртлек тә бии.

### КҮГӘРЧЕН

Күгәрчен баласы, күрексез булса да, үскәч күгәрчен була, ди.
Күгәрчен булып туган кош карга булып үлми.
Күгәрчен күгәрчен белән аулана.
Күгәрчен күгәрченне «гөлдер бу-у» дип мактаган.
Күгәрченнең бодае һәркайда.
Ут чыкса – күгәрчен су ташый, чыпчык чүп ташый имеш.

### КҮКЕ

Алдан кычкырган күкенең башы таз була.
Иртә кычкырган күкенең башы авырта.
Күке баласын карга асрар, туйдыралмый күзе чыгар.
Күке гыйшык тота, баласын карга карый.
Күке күкәйне үзе салган, баласын каргага тапшырган.
Күке кычкырмый җәйнең яме булмый.
Күкегә оя кирәкми.

### ЛАЧЫН

Ике лачын сугышса, ябалакка йон булыр.
Лачын кошка һава кадерле.
Лачыннан ни файда бар, оча алмаса.
Үлгән лачыннан тере карчыга артык.

## ЛӘКЛӘК

Ләкләк, гомере үтәр әләкләп.

Ләкләк тә булдымы кош: яз килер дә кыш китәр.

Ләкләкнең килешен сорама, китешен сора.

## ӨКЕ

Өке – йоны белән, былбыл – өне белән.

## ПЕСНӘК

Песнәк диңгезне яндыра алмый.

Песнәкнең үзенә күрә бизмәне, бүдәнәнең үзенә күрә бакрачы.

Эшләки (песнәк), эшләки, эшләмәсәң хаста ки, дип әйтә ди эшләки кошы.

## САЕСКАН

Саескан бер ботакта озак утырмас.

Саескан җиргә бер кунганда кырык сикерер.

Саескан, кеше йөрүен үртәп, үз йөрүен оныткан.

Саескан сагыз чәйни, карганың күзе кайный.

Саескан сайрау белән сандугач булмас.

Саескан саклыгыннан үлми, соклыгыннан үлә.

Саескан, сандугач кебек сайрармын дип, шыкырдык булып калган.

Саескан, туры очса да, кыек яшәр.

Саескан тутый телен әләкләп сакау калган.

Саескан чукыган белән тук булмас.

Саескан, үзе бур булгач, оясының түбәсен каплаган.

Саесканның койрыгы үзеннән шәп.

Туры очкан саескан, төшеп, урлап май эчкән.

## САНДУГАЧ, БЫЛБЫЛ

«Алтын оям, үз җирем!» – дип әйтте, ди, бер сандугач.

Бака кычкыра башлагач, сандугач телдән калыр.

Бакчасыз йортка былбыл кунмас.

Былбылга бер гөл дә җитәр, үгез бөтен бакчаңны таптар.

Былбылны алтын читлеккә япсаң да, үз тал-тирәген сагынып сайрар.

Былбылның өне бар, тургайның тубыр теле бар.

Былбылның өне татлы, тутыйның теле татлы.

Оясыз сандугач сайрамый.

Өй артында куагың булса, сандугач кунагың булыр.

Сандугач булсаң, сайрый да бел.

Сандугач, кечкенә булса да, мактаулы кош.

Сандугач сайраганда тургай тик тора.

Сандугач сайрап җиңәр, карга кычкырып җиңәр.

Сандугач та үзе бала чыгарган тигәнәлеген сагынып сайрый, ди.

Сандугач – читлектә, карга – иректә.

Сандугач шәп сайраган өчен читлеккә эләгә.

Сандугач юк елны карга дан тотар.

Сандугач үз кадерен үзе белер.

Сандугачлар да, – тигәнәк башы, ди, йортлары – «үз илем, үз җирем» дип сайрыйлар, ди.

Сандугачлар язда гына сайрыйлар.

Сандугачны сайрарга өйрәтмиләр.

Сандугачны сүз белән туйдырмыйлар.

Сандугачны өйгә җибәрсәң, мәчеңне читлеккә яп.

Сандугачның күзе тирәктә, карганыкы – тизәктә.

## СИРТМӘКОЙРЫК

Сиртмәкойрык: «Минем койрыгым сиксән пот», – ди имеш.

## СЫЕРЧЫК

Сыерчык бала чыгарганчы гына сайрый.

Сыерчык, диңгез артына китсә дә, үзе туган ояга кайта.

Сыерчык сыердан курыкмас.

Сыерчык теле ачылмаган балага тел алып килә.

## ТАВИС

Тавис – каурые белән матур.

Тавис киенер дә ясаныр, аккош коеныр да сыйпаныр.

Тавис койрыгына ышаныр.

Тавис кошы койрыгына бакса – кинәнгән, аягына бакса – җирәнгән, ди.

Тавис, тәпие ямьсезлеген күргәч, койрыгы белән каплаган.

Тависның күлмәге ефәк булса да, аягы ыштыр булыр.

## ТАРТАЙ, ТАРТАР

Бер тартарга дөнья тар.

Карга теләген теләшкән тартай үзенә давыл китергән.

Тартар гомере «тарт-тарт!» дип үтәр.

Тартар теленнән табар.

Тартарның теле башына җитәр.

## ТӘВӘ КОШЫ, ДӨЯ КОШЫ

Дөя кошы башын комга тыгып кына аучыдан яшеренә алмый.

Дөя кошын да арбага җигәләр.

Тәвә кошы, «оч» дисәң – «мин тәвә», «йөк тарт» дисәң – «мин кош», ди икән.

## ТОРНА

Ана торна күкәй салганда, торыллык (ата торна) ботын ера.

Йөз чыпчык чырылдавыннан бер торнаның торылдап куюы артык.

Торна да кыйбланы ташлап туган җиренә кайта.

Торна каурыен салган – аяклары да томшыгы калган.

Торна күзе тарыга төшкән.

Торна күкәй салганда карганың арты ертылган.

Торна оятын оятлап, ябалак урман түренә качкан.

Торна торган суына кайта.

Торнадан курыккан тары икмәс.

Һавадагы торнага авызың ачып торма, ага!

Һавадагы торнадан кулыңдагы чыпчык артык.

Һавадагы торнаны тотам дип, кулыңдагы чыпчыкны җибәрмә.

## ТОРЫМТАЙ

Торымтайдан очкыр кош булмас, тургай ташлап каз алмас.

## ТУКРАН

Тукран башы авырткач «чукымам, чукымам» дисә дә, авыртуы беткәч «чукырмын, чукырмын» дип әйтә, ди.

Тукран, башы авыртмыйча, тукылдавын куймас.

Тукран кич тәүбә итәр, иртән онытыр.

Тукран тәүбә итәр, тәүбәсе кырын китәр.

Тукран тәүбәсе туклык бирмәс.
Тукранның балтасы борынында.
Урманда тукран да солтан, ди.

## ТУРГАЙ

Сарыкка сыенса, тургай да сау кала.
Туксансыз тургай чырламас.
Тургай килгән – тугыз көн кар калган.
Тургай котырса – бөркеткә чабар, эт котырса – иясен кабар.
Тургай, яңгыр тисә, баласын яшерә, рашкы тисә, үз башын яшерә.
Тургайның юашлыгын чебеннәрдән сора.

## ТУТЫЙ

Тутый аягын күреп хурланды, буен күреп сырланды.
Тутый сөйли белсә, күркә тик тора белә.
Тутый сөйләшергә өйрәнер, кеше була алмас.
Тутыйны читлеккә теле кертә.

## ЧЫПЧЫК

Аучы чыпчыкка тозак кормас.
Ил өстендә чыпчык үлми.
Илен-җирен сөйгән чыпчык үз җирендә үлмәс.
Иртә торган чыпчык тешен арчый.
Иртәнге чыпчык тешен казыр, соңгы чыпчык күзен казыр.
Карт чыпчыкны кибәккә алдый алмассың.
Кулдан ычкынган чыпчыкны яңадан тота алмассың.
Сугышканда чыпчыклар кешедән курыкмыйлар.
Чыпчык дулап киртә җимерә алмас.
Чыпчык – илендә, җикән – күлендә.
Чыпчык кыбырдамый торалмый.
Чыпчык, симерсә дә, батман килми.
Чыпчык та тутый кош кызын сораган, ди.
Чыпчык та әйтә «үз чытырым» дип.
Чыпчык утырмас, утырса да тик тормас.
Чыпчык «чыбыгым» ди, карга «каеным» ди имеш.
Чыпчыкка – муеннан, каргага – тездән.
Чыпчыкның да үзенә күрә бизмәне бар.
Чыпчыкның да үзенә күрә моңы бар.

## ШӘҮЛЕГӘН

Шәүлегән су чыгарган, карга кинәнгән.

## ШОҢКАР

Асыл шоңкар каз алса, канатын канга тигезмәс.
Ике шоңкар талашса, бер каргага җим булыр.
Кыягы бөтен шоңкар юк.
Очкан кошның барысы да шоңкар түгел.
Шоңкар юкта ябалак мәйдан тотар.
Шоңкардан кош куркыр, тургайдан корт куркыр.

## ЯБАЛАК

Былтыр үлгән ябалак быел башын күтәргән.
Былтыр үлгән ябалакның быел исен чыгарма.
Үзе ябалак булса да, үзен лачын атаган.
Чырайсыз ябалакны урман да куган, авыл да куган.
Ябалак асрап кош чөйгән ауга чыгып котаймас.
Ябалак елый, урман йоклый.
Ябалак күрмәгәнгә кояш гаепле түгел.
Ябалак оятыннан карчыга ояла.
Ябалакка көннән төн якты.
Ябалакның планын куян белмәс.
Ябалактан – йон, бүдәнәдән – май.
Ябалактан карчыга тумый.

## ЙОРТ КОШЛАРЫ, КОШЧЫЛЫК. КАЗ (КЫР КАЗЫ)

Аерылган каз тупланган каргага җим булыр.
Алдан очкан – ата каз, арттан очкан – ана каз.
Ана каз йомырка басканда, ата каз янында биер.
Ана каз каңгылдамаса, ата каз бармас.
Ата-аналы казга унике бәбкә дә аз.
Балалы казга җим тимәс.
Бәбкә чыкса – каз булыр, яңгыр яуса – яз булыр.
Каз артыннан тавык Идел аша очмас.
Каз арыкласа да, карга булмас.
Каз – бергә, козгын аерым очар.
Каз – каз белән, үрдәк үрдәк белән очар.
Каз какылдаудан туймас, үрдәк бакылдавын куймас.

Каз канаты каләм булыр.
Каз канатына су йокмас.
Каз килсә – яз килә.
Каз китә дип, карга да киткән.
Каз тиресен иләсәң дә, каеш булмас.
Каз өчен тавык җәл түгел.
Каз үзе чүлдә булса да, күзе күлдә булыр.
Каз үрдәкне талый, үрдәк тавыкны талый.
Казга кайсы казанга салсалар да барыбер.
Казны канатыннан бәйләсәң, күпме талпынса да, очалмас.
Оясын пычраткан каз басып торыр.
Сәгать уникене суккач, каз йомырка сала башлый.
Утырган каз урынын белә.
Ялгыз казның тавышы чыкмый.
Яхшы каз оясын пычратмас.

## КҮРКӘ

Кабарыну – күркә гадәте.
Күперенү күркәгә генә килешә.
Күркә җилдән симерә.
Күркә кызылга үч.
Күрше авылның күркәсе – үз авылыңның үрдәге.
Кызыл күрсә, күркәнең гайрәте килер.

## ТАВЫК, ЙОМЫРКА, ЧЕБИ

Алмаган тавык, салмаган йомырка, чебешләрне сата башлама.
Ана тавык «кырт-кырт» килеп торыр.
Аннан әйбер алганчы, тавыктан сөт саварсың.
Аның тавыгы юргалый.
Аңгыра тавык көшел өстендә ач йоклый.
Аңгыра тавык чүплек башына йомырка салыр.
Балалы тавык – гаугалы халык.
Берәүнең чебешен үтерсәң, тавык түләрсең.
Бүленгән тавыктан бүленмәгән күкәй артык.
Дүрт аяклы тавык юк.
Җөйсез йомырка була, сөяксез бәрәңге була.
Ике тавыкка азык аера алмый.
Инкубатор чебеше ата-анасын танымас.

Инкубатор чебеше әрсез булыр.
Йомырка кырлы булмас.
Йомырка салган тавык үзе кытаклый.
Йомыркадан әле яңа гына чыккан.
Йомыркадан җөй тапкан, беләүдән тут тапкан.
Йомыркадан җөй эзләмә.
Кайчагында тавык та әтәч булып кычкыра.
Кап-кара тавык та ап-ак йомырка сала.
Кеше тавыгы каз кебек, йомыркасы баш кебек.
Кеше тавыгы күркә булып күренә имеш.
Кешенең чебешен ашасаң, казыңны бирерсең.
Киләчәк тавыктан килгән күкәй яхшы.
Кирәгеңне тырнап-казынып табарга тавыктан өйрән.
Кичә йомыркадан чыкты, бүген кабыгыннан җирәнә.
Койрыгы кискән тавык кебек.
Күкәй салмас тавык көн элгәре кытаклый.
Күкәй эчендәге сары кебек.
Күкәйдәге бәбкә су сорый.
Күп кытаклаган тавык йомырканы аз сала.
Күпме кыркылдаса да, тавык очып тау ашмый.
Күрше тавыгы күршегә күркә булып күренә.
Кызыл йомырка көнендә кыйммәт.
Кысыр тавык күп кытаклый.
Кыткылдаган тавыкның барысы да күкәй салмас.
Мал башы – тавык.
Мая башы – бер күкәй.
Мая булса, күкәй булыр.
Соңга калган йомыркадан сукыр чебеш чыгар.
Суга төшкән чебеш кебек.
Сукыр тавык юлга чыкса, буран булыр.
Сукыр тавыкка бакра да бодай.
Сукыр тавыкның төшенә тары кергән, чүпләп бетерә алмагач тагы кергән.
Сырлы күкәй сабан туенда гына була.
Тавыгы йомырка салмаган, чебешләрне сатарга уйлый.
Тавык «кикрикүк» дигән белән әтәч булмас.
Тавык белгәнен кычкырыр.
Тавык белән ят, әтәч белән тор.
Тавык берәр бөртек чүпләп тә тук тора.

Тавык берәр йомырка сала.
Тавык канат какса да очалмас.
Тавык кетәгенә кертү.
Тавык кош түгел.
Тавык көл тибәр – үз башына сибәр.
Тавык күкәй салмас борын чебешен ашамыйлар.
Тавык күп җирдә чүп күп.
Тавык кытакламаса, күкәй саласын кем белә.
Тавык мие эчкән.
Тавык очса – тамга куна, лачын очса – тауга куна.
Тавык сала, карга ала.
Тавык симерсә, арты бөрешә.
Тавык та йомырка салганчы гына кытный.
Тавык та маясыз салмый.
Тавык та тырнап туена.
Тавык та үргә карап су эчә.
Тавык тешенә тары кергән, таң атканчы ашап бетергән.
Тавык тибенсә, чүп чыга.
Тавык төшенә тары керә, ашамаса тагы керә.
Тавык түгел, йолкып ашамаслар.
Тавык үз кетәген мактый.
Тавык чүпләнеп тамак асрый.
Тавык чүпләп бетергесез.
Тавык чүпли-чүпли күзеңне чыгарыр.
Тавык, бер күкәй салганчы, бөтен мәхәлләне аякка бастырыр.
Тавык, йомыркасы артына җиткәч, урын эзли.
Тавык, күкәй салмас борын, оя басмый.
Тавык, тауга менгәч, әтәч булып кычкырган, ди.
Тавыкка күз салып, сарыктан колак каккан.
Тавыкны күкәй өйрәтә.
Тавыкны күкәй өйрәтми.
Тавыкның азганы әтәч булып кычкырыр.
Тавыкның астына күкәй куймасаң, чебеш кайдан килсен.
Тавыкның ерак сәфәре – ындыр.
Таң атырын тавык белер, көн батарын кәккүк белер.
Таңдагы тавыктан бүгенге йомырка артык.
Тоз ашаган тавык әтәч булып кычкырыр.
Тонган йомыркадан бәбкә чыкмас.

Тырнанмаган тавыкның тамагы туймый.
Уртак тавыктан ялгыз йомырка яхшы.
Ут эчендә тоткан йомырка сытылмый.
Үләсе килгән чебеш кое кырыенда йөрер.
Үскән чебеш тавык артыннан йөрми.
Хәтерсез тавыкның чебиләрен карга ташыр.
Чебешне көз саныйлар.
Чебешне яз санамыйлар, көз саныйлар.
Чебиле тавык тилгәннән курка.

## ӘТӘЧ

Акын әтәче дә күкәй сала.
Аның әтәче дә кубыз уйный.
Атач әтәчнең бүксәсе дә сул якта булыр.
Әтәч – үз чүплегендә патша.
Әтәч кычкырса: «Хатыным күп, түшәгем юк», – дияр имеш.
Әтәч синнән зирәк булмасын, син әтәчтән зирәк бул.
Әтәч үлгән, күзе чүплектә калган.
Әтәч чүплек башын бакчага алыштырмас.
Әтәчкә дә чебеш туйдырырга туры килә.
Әтәчнең күрке – кикреге дә койрыгы.
Бер куразны җиде кеше суймый.
Булыр әтәч йомырка эчендә үк кычкырыр.
Вакытсыз кычкырган әтәчне суеп ашыйлар.
Ике әтәч сугышканда тавыклары кытаклар.
Иртә кычкырган әтәчнең түбә чәчен йолык.
Йомыркадан чыкканчы әтәч булган.
Карт әтәч кычкыручан була.
Кечкенә булсаң да, әтәч бул.
Куразга «кычкыр» дип әмер бирмиләр.
Кырык ел тавык булганнан бер көн әтәч булганың артык.
Соң кычкырган әтәчнең тавышы ягымсыз.
Сугышчан әтәч беркайчан да симез булмый.
Тавык кытаклый дип, әтәч тә кытаклаган.
Торна күк атлыйм дип, әтәчнең чаты аерылган.
Туйга да шул әтәч башын өзәләр, үлек ашына да.
Үз чүплегендә әтәч тә батыр.

## ҮРДӘК, КЫР ҮРДӘГЕ

Аларның үрдәге дә каз кебек.

Аптыраган үрдәк алдына да, артына да йөзәр.

Аптыраган үрдәк күлгә арты белән чумар.

Аптыраган үрдәк койрыгы белән шуа.

Артына су кергәч үрдәк кенә йөзә.

Аткан саен киек үрдәк эләкми.

Аткан саен үрдәккә тими.

Балалы үрдәк күлдән китмәс.

Башчы үрдәк алдан очар.

Берәүнен үрдәген ашасаң, казыңның аягыннан тотып тор.

Бөтен дөньяны су алса, үрдәккә ни гамь бар.

«Йорт башыңны сат та мине ашат!» – дип әйтә, ди, үрдәк.

Йөзә белмәгән үрдәк суга кермәс.

Кире киткән үрдәк күлгә арты белән чума.

Курыккан үрдәк башын ташлар да артын ярыр.

Күгәл (*кыр үрдәге*) күленә күрә чумар.

Симертергә ябылган үрдәк ашаудан туймый.

Үрдәк алсаң, каз бирерсең.

Үрдәк ашаганда: «Ашасам, өй кыегы да бар әле», – дип, хуҗасының өй кыегына карап ала, ди.

Үрдәк ашаганда: «Бөлдерим, бөлдерим, өй түбәсен төшерим, дранчага калдырыйм», – дип ашар имеш, ди.

Үрдәк баласы күкәйдә үк суны белә.

Үрдәк баласын суда йөзәргә өйрәтмиләр.

Үрдәк биргән – каз көтәр.

Үрдәк бирсәң, каз алырсың.

Үрдәк бәбкәсе, тавык астында туса да, суга тартыр.

Үрдәк йомыркасын тавык басар, бәбкәсе суга качар.

Үрдәк, ничаклы ыспайланса да, аккош була алмый.

Үрдәк очса, каз калыр.

Үрдәк: «Ризыгымның өйдәгесен тавык ашый, судагысын балык ашый», – дип кайгырыр имеш.

Үрдәк суда үлми.

Үрдәк: «Судагы качмас, өйдәге качар», – ди имеш.

Үрдәк теләген теләшкән тавыкның оясын су басар.

Үрдәк: «Хуҗаның түбәсе такта, саламга калганчы ашыйм әле», – дип әйтә, ди.

Үрдәк, үзенә ышанмаса, әкәлә йотмый.

Үрмәкүч тозагына үрдәк эләкмәс.
Үрдәк биреп каз алган.
Үшән үрдәк алдан очар.
Янтыклы җирдә суна бар.

## КЫРГЫЙ КОШЛАР ҺӘМ КОШ АУЛАУ ТУРЫНДА

Авыз белән кош аулап йөрү.
Агач башына әүвәл нинди кош кунса, кырына шул кунар.
Асрый белгән кешегә – асыл кош, белмәгәнгә – кара кош.
Асыл кош – аягыннан, сак балык – саңагыннан.
Асыл кош иягеннән асылына.
Асыл кошның баласы алдына куймый аш җимәс.
Бала кош очар, кунар агачын тапмас.
Бала кош очарын белер, кунарын белмәс.
Бала кошның авызы зур булыр.
Балалар асраганда кош та төксәрә.
Балалы коштан җим артмый.
Бер канат белән очылмый.
Гарип кошның баласы күп булыр.
Гарип кошның оясы һәркайда.
Җим белән кош очар, азык белән ат туяр.
Ике канат, бер койрык.
Исәпләмәгән кош урманда ботак тапмас.
Йортта озак асралган кош мәңгегә очалмас.
Йортыгызда очкан кош та күренми.
Канат алырга бардык, койрыксыз кайттык.
Канатсыз очып китмә.
Канатсыз туган оча алмас.
Канаты бәйле кош очмас.
Канаты бәйсез азат кош җирдәге тозакка үзе төшәр.
Килеп кунмыйча, очып китмә.
Кош баласы, күп очса да, кунарга оя тапмас.
Кош баласы, оясында ни күрсә, очканында шуны күзәтер.
Кош бара-бара төз китәр.
Кош җиткән җиренә кунар.
Кош канаты белән очар, койрыгы белән кунар.
Кош күктә, тозак җирдә.
Кош кунмаган агач юк.

Кош сайравыннан билгеле.
Кош та сайламыйча куакка кунмый.
Кош һавада сынала.
Кош читлектән кая очса да, бар җир дә аңа оҗмах күренер.
Кош эзләгән күккә карар, ат аяган җиргә карар.
Кош оясында ни күрсә, очканда да шуны кыла.
Кошлар да кушы белән.
Кошларга иректә очу алтын читлектә торудан артыграк.
Кошны канаты очыра.
Кошны кош белән аулыйлар.
Кошның да туган оясы бар.
Кошның кошы бала өчен капкынга эләгә.
Кошсыз куак – котсыз куак.
Кошына күрә тозагы.
Көчсез кошның оясы бөркет янында булыр.
Кулга өйрәнгән кош далада адашыр .
Кулда асралган кош ерак очмас.
Кулыңдагы кошны очырып, һавадагы торнаны эзләмә.
Куркак кош оясын олы юл өстенә ясый.
Курыккан кош куактан өркер.
Күзәми очкан кош кунарга агач тапмас.
Очар кош үзен ауга тоттырыр.
Очасы кош ботакның очына кунар.
Ояны ана кош ясый.
Өметле кош күкәйдә дә җырлый.
Өстеннән кош та очырмау.
Талпынган кош очмый калмас.
Тарландагы тартай, кырдагы куян.
Теләмәгән агачына кош та оя ясамый.
Тисә – кошка, тимәсә – бушка.
Тозакчы үзе күренмәс, җимен генә күрсәтер.
Түбән очкан кош югары кунар, югары очкан кош түбән кунар.
Уйламый очкан кош кунарга тал тапмас.
Һәр кош канатына күрә оча.
Һәр кош очып лачын булмый.
Һәр кош үз көтүендә яхшы.
Һәр кош үз оясын үзе корыр.
Һәр кош үз оясына карап оча.

Һәр кош үз оясында ирекле.
Һәр кошның да ите ашалмас.
Һәр кошның койрыгы канатына күрә була.
Һәр кошның үз тавышы үзенә хуш.
Читлек, алтын булса да, читлек булыр.
Читлеккә өйрәнгән кош ирektә башын югалтыр.
Чыкмаган канат белән очып булмый.

ЭЧТӘЛЕК

Кереш сүз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
Сүзлекнең төзелеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 9
Файдаланылган чыганаклар исемлеге . . . . . . . . . . . 12
Шартлы кыскартылмалар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
Татарча-русча-латинча орнитонимнар . . . . . . . . . . 16
Отряд һәм семьялык исемнәре . . . . . . . . . . . . . . . 91
Татар телендәге төп орнитонимнар исемлеге . . . . . . . . . . 95
Рус телендәге төп орнитонимнар исемлеге . . . . . . . . . . 103
Русча, татарча кош атамалары күрсәткече
(алфавит тәртибендә) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 113
Татар диалектларында һәм сөйләм телендә кулланылган
орнитонимнар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 156
Кошлар белән бәйле сынамышлар, мәкаль-әйтемнәр,
канатлы сүзләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 160

Справочное издание

**Сафина Эльвира Ирфатовна**

**ТАТАРСКО-РУССКО-ЛАТИНСКИЙ СЛОВАРЬ ОРНИТОНИМОВ**

Компьютерная верстка *Н.Т. Абдуллиной*

Подписано в печать 30.10.2018 г.
Формат $60 \times 84^{1}/_{16}$. Бумага офсетная. Гарнитура Times New Roman
Печать офсетная. Усл. печ. л. 10,7. Уч.-изд. л. 6,0. Тираж 600 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20